### ЯЗУЧЫ ЭЗЛӘРЕННӘН

Гомәр Бәшировның туган авылына сәяхәт

> 6

### МӘХӘББӘТ ӨЧЕН – АКЧА?

Никахны саклауның яңа ысулын тәкъдим итәләр

> 7

### БУШ ТӨЙМӘ

Үзебездә җитештерелгән даруларның файдасы бармы?

> 15

# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 65 (29032) | Җомга | 12 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

# ЙОЛДЫЗНЫ КҮТӘРИК

## ЯНЫП БЕТКӘН ТАТАР АВЫЛЫН МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЯРДӘМЕННӘН ТАШЛАМЫЙ

**1,5 сәгать. Гөрләп яшәп яткан авылны тулысы белән диярлек юкка чыгарырга әнә шулкадәр вакыт җиткән. 7 майдан 8 майга каршы төндә Курган өлкәсендәге урман янгыннары Шадрин районындагы Йолдыз (элеккеге атамасы – Эчкен) татар авылын тулысынча диярлек утлы күмергә әйләндерде. 377 хуҗалыкның нибары 90ы гына исән калган. Алары да ярты-йорты гына. Иң аянычлысы – үз йортларыннан чыга алмыйча һәлак булган кешеләр бар.**

> 5

**Ишетми калмагыз**

Якын араларда Татарстанда һәм тагын 11 төбәктә гадәттән тыш зур дәрәҗәдә янгын куркынычы саклана. Россия Гидрометеоүзәге җитәкчесе Роман Вильфанд әйтүенчә, Идел буе федераль округының көньяк-көнчыгышында, Уралның көньягында – дүртенче класслы, Татарстан, Удмуртия, Самара, Чиләбе өлкәләрендә һәм тагын берничә төбәктә бишенче класслы янгын куркынычы фаразлана. Ут белән аз гына саксызрак эш иткән очракта да һава торышы янгын таралуга ярдәм итәчәк, дигән сүз бу.

Узган елда Татарстанда фәкыйрьләр саны, 1990 нчы елларның уртасыннан бирле, иң түбән күрсәткечкә төшкән. 2022 елда республикада 940,3 мең кешенең айлык кереме 60 мең сумнан күбрәк тәшкил иткән. «Реальное время» басмасы «Татарстанстат» мәгълүматларына таянып хәбәр иткәнчә, 2021 елдагы белән чагыштырганда мондыйларның өлеше, артып, 17,5 процентан 23,5 процентка кадәр җиткән. Республикада яшәүчеләрнең 14,3 проценты (572,2 мең кеше) аена 25 меңнән 60 мең сумга кадәр эш хакы ала. Халыкның бу өлеше 2021 елдагыга караганда 2,2 процентка арткан. Ә инде иң киң таралган керем күләме – 27 меңнән 45 мең сумга кадәр. Халыкның 28,6 проценты (1,1 миллион кеше) шундый хезмәт хакына эшли.

Шул ук вакытта айлык кереме 7 мең сумнан артмаучылар да бар, 36 мең кеше әнә шундый аз акчага яши. Әмма аларның саны кими: 2021 елда бу өлеш 2% кына тәшкил иткән. Шуны да билгеләп үтик: Татарстанда кереме фәкыйрьлек чигеннән кимрәк күләмдәге (13762 сум) кешеләр өлешенең иң югары күрсәткече 2000 нче елда теркәлгән. Ул чагында бу күрсәткеч 33,2% тәшкил иткән.

Сүз уңаеннан, узган елда республикада яшәүчеләр кеременең гомуми күләме 2,156 триллион сум тәшкил иткән. 2021 елдагы күрсәткечтән (1,852 триллион сум) 304,5 миллиард сумга күбрәк бу. Җан башына уртача керем исә – аена 46249 сум.

Россиядә табибларның өчтән бер өлеше чамасы 55 яшьтән өлкәнрәк. Медицина хезмәткәрләре арасында яшь белгечләр өлеше дә шул чама. «РИА Новости» агентлыгы Сәламәтлек саклау министрлыгы хисабына таянып хәбәр иткәнчә, хәзерге вакытта сәламәтлек саклау өлкәсендә табибларның 28 проценты һәм урта медицина хезмәткәрләренең 21 проценты – 55 яшьтән өлкәнрәкләр. Яшь белгечләр өлеше (36 яшькә кадәр) исә – 31% (табиблар) һәм 27% (урта медицина персоналы). Россиянең күп кенә төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда медицина хезмәткәрләрен эш урыннарына җәлеп итү буенча чаралар күрелә. Аерым алганда, апрель ае башында республиканың Министрлар Кабинеты мәҗбүри медицина иминияте программасына кертелмәгән ашыгыч медицина ярдәме, беренче ярдәм күрсәтүче табиблар, шәфкать туташлары өчен махсус социаль түләүләр билгеләде.

# ЭШКӘ БИРСӘҢ ЧЫН КҮҢЕЛ

**Татарстан белән Иранны тыгыз элемтәләр бәйләп тора. Бу хакта Татарстан Хөкүмәт йортында узган чарада билгеләп үттеләр.**

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Иран Ислам Республикасының Казандагы яңа генераль консулы Давуд Мирзахани белән очрашты. Рәис аны Татарстанга эшкә билгеләнүе белән котлады.

– Иран белән мөнәсәбәтләрнең дәрәҗәсен, тыгыз икътисадый һәм мәдәни элемтәләрне исәпкә алып, сезнең Татарстандагы эшчәнлегегез нәтиҗәле һәм кызыклы булыр дип ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис әйтүенчә, республика Россия – Иран мөнәсәбәтләре кысасында ике арадагы хезмәттәшлекне үстерүгә зур әһәмият бирә. Алга таба сәүдә-икътисадый, мәгариф һәм фән, туризм, мәдәният өлкәләрендә бергәләп эшләргә мөмкин, дигән фикер җиткерде Рәис. Очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов киләсе атнада башкалада узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый җыены турында да искә төшерде. Билгеле булганча, форумда Иран делегациясе дә катнаша. Алар арасында рәсми һәм эшлекле даирә вәкилләре булачак дип көтелә.

Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы мәгълүматларына караганда, Иранны Россиядән сарык ите, кукуруз, арпа кебек бөртекле культуралар сатып алу кызыксындыра. Безгә исә нефть химиясе продуктлары, төзелеш материаллары, кипкән җиләк-җимеш озата башламакчылар.

– Иран делегациясе республикага форумга кадәр берничә көн алдан киләчәк. Аларны каршы алу өчен Россия Сәүдә-сәнәгать палатасы белән берлектә әзерлек эшләре алып барыла. Кунаклар Татарстандагы индустриаль паркларны да караячак дип көтелә. «KazanForum» мәйданында бизнес-миссиягә йомгак ясалачак, – дип сөйләде Татарстан инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина Министрлар Кабинетында узган брифингта.

**Фикер**

**Сергей КАТЫРИН,**
**Россия Сәүдә-сәнәгать палатасы Рәисе:**

– Татарстан белән Иранны Россия – Иран эшлекле мөнәсәбәтләре кысасында тыгыз элемтәләр бәйләп тора. Казанда 2007 елдан бирле Иранның генераль консуллыгы, «Мир Бизнес Банк» Иран акционерлары филиалы эшли, Татарстан югары уку йортларында Иран студентлары белем ала, мәдәният һәм фән өлкәсендә хезмәттәшлек җәйга салынган. 2022 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан белән Иран арасында товар әйләнеше 200 миллион долларга якын тәшкил иткән. Әлеге күрсәткечне икеләтә арттыру өчен икътисадый мөмкинлекләр җитәрлек. Эш юнәлешләрен билгеләргә Россия Сәүдә-икътисадый палатасы каршындагы Россия – Иран эшлекле советы ярдәм итә. Иран делегациясенең Татарстанга килүе – җавап йөзеннән оештырылган эш сәфәре. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның 2022 елның көзендә Иранга эш сәфәре ике яклы хезмәттәшлеккә яңа мөмкинлекләр ачты.

(«РБК-Татарстан»га биргән әңгәмәсеннән)

# КУНАК АШЫ

**Татарстан башкаласы кунаклар каршы алырга әзерләнә. Киләсе атнада Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый җыены узачак. Анда дөньяның 70кә якын иленнән 15 меңләп кеше катнашачак дип көтелә. Форум көннәренә башкала кунакханәләрендә буш урыннар калмаган да диярлек инде.**

«Татар-информ»

«Соңгы тапкыр мондый хәл Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты узганда булган иде...» Башкаладагы кунакханә хуҗалары әнә шулай ди. Алар, җиң сызганып, кунаклар каршы алырга әзерләнә. 18–20 майда узачак «KazanForum»га дөньяның 70кә якын иленнән, Россиянең 30лап төбәгеннән катнашучылар киләчәк дип көтелә. Май башыннан бирле башкаладагы кунакханәләрнең кереме 15 процентка арткан инде. Киләсе атнада эш тагын да кызурак булачак, диләр. Казанның туризмны үстерү комитеты директоры Дарья Санникова сүзләренә караганда, форум көннәрендә биш йолдызлы кунакханәләр 96 процентка тулган. Кунакларны хәләл стандартлары буенча каршы алачаклар.

Форумда катнашучылар арасында «Галәм гүзәле Бәхрәйн – 2022» титулы иясе Эвлин Абдулла-Хәлифә дә бар. Гарәп илләре гүзәле Казанда хәләл матурлык турында чыгыш ясаячак дип фаразлана. Хатын-кызлар өчен хәләл ял, хәләл фитнес кебек мәсьәләләрне дә күтәрмәкчеләр. Форумда Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Төркия, Һиндстан, Сербия кебек илләрдән эшлекле гүзәл затларны көтәләр. Җыенда тәүге тапкыр «Хәләл эшмәкәр хатын-кыз» премиясен тапшырачаклар.

Табибларга да эш арткан. Форум көннәрендә эшлекле һәм мәдәни программалар узачак мәйданнарда, шулай ук кунаклар яшәгән урыннарда медицина ярдәмен хәләл стандартлары буенча күрсәтәчәкләр.

– Ислам форумының үзенчәлекләрен исәпкә алып, һәр медпунктта икешәр мобиль бригада – ир-ат табиблар һәм хатын-кыз табиблардан торган төркемнәр эшләячәк. Аларның өс киемнәре дә хәләл стандартларына туры киләчәк. Форум чараларының баш табибы итеп Татарстанның баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов билгеләнде, – дип сөйләде Татарстан сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин.

Җыен кунакларына стационар ярдәмне шул исәптән РКБ һәм ДРКБда күрсәтәчәкләр. Моның өчен хастаханәләрдә намаз уку бүлмәләре дә оештырылачак. Роспотребнадзор белгечләре исә форум катнашучылары яшәячәк кунакханәләрдә һәм туклану урыннарында тикшерү башлаган.

Исегезгә төшерәбез: Казанда икътисадый форум 2009 елдан бирле үткәрелә.

– Ил Президенты Владимир Путин күп тапкырлар, Россия һәрвакыт мөселман дөньясы белән үзара хезмәттәшлекне киңәйтәчәк һәм тирәнәйтәчәк, дип белдерде. Безнең илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуда төп рольне «KazanForum» уйнарга тиеш, ул быелдан федераль дәрәҗәдә үткәрелә, – диде башкалада узган халыкара икътисадый форумга әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты утырышында Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары, оештыру комитеты рәисе Марат Хөснуллин.

**Районнарда ни хәлләр?**

**Балтач**

Смәел авылы кызы Нурсинә Галиева 5–7 май көннәрендә Санкт-Петербургта узган колляскада бию буенча Россия чемпионатында уңышлы чыгыш ясап, өч медальгә ия булды. «Беренче көнне фристайл категориясе буенча ярыштык, икенче урынга лаек булдым. Икенче көнне – гомуми программа, анда 5 бию рәттән биедек, беренче урын яуладым. Өченче көнне ансамбльләр арасында ярыш булды, без Мәскәү командасы белән биедек, өченче урын алдык», – ди Нурсинә Галиева.
(«Хезмәт»)

**Әлмәт**

Әлмәт картиналар галереясында «Батырлык үлемсез» проекты кысасында Бөек Ватан сугышы герое Барый Йосыповның бюсты ачылды. Аны Санкт-Петербургтагы Дәүләт Рус музееннан кайтардылар. Чарада Барый Йосыповның туганнары, Татарстан Мәдәният министрлыгы, Әлмәт районы администрациясе вәкилләре һәм башкалар катнашты. Әлмәт авылында туган герой БМ-13 реактив артиллериясенең легендар «катюша» хәрби машиналарының тәүге командирларының берсе буларак тарихка кереп кала. 1942 елда Йосыпов Ленин ордены белән бүләкләнә. Шактый еллар «катюша» өчен кадрлар әзерләгән гвардия өйрәнү бригадасын җитәкли. 1946 елда Барый Йосыпов икенче тапкыр Ленин ордены белән бүләкләнә. 1981 елда Мәскәүдә вафат була.
(«Татар-информ»)

**Кайбыч**

Кошман авылында кошчылык фермасы ачылды. Шушы авылда яшәүче Динә Сайранова, «Агростартап» бәйгесендә катнашып, 1 миллион 500 мең сумга якын грант откан иде. Әлеге грант акчасына 5 мең тавык үстерү өчен ферма төзеткәннәр. Эшчәнлекне тормыш иптәше – фермер Рушан Сайранов белән бергә алып баралар. Ферманы ачуда район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин, башкарма комитет җитәкчесе Алексей Макаров, авыл җирлеге башлыгы Лилия Сафина һәм башкалар катнашты. Хәзерге вакытта тавык фермасының беренче бинасында йомырка сала торган 3 мең кызыл тавык, икенчесендә 5 мең баш бройлер чеби асрыйлар.
(«Кайбыч таңнары»)

**Актаныш**

Карач авылында нибары бер кеше – фермерлык белән шөгыльләнүче Тәлгать Арсланов кына яши. Шуңа да карамастан, авылда бәйрәмнәр узып тора, Бөек Җиңү алып килгән батырларның рухы да онытылмый. Моннан берничә ел элек Карачта читтә яшәүче авылдашлар ярдәме белән һәйкәл төзелде. Тәлгать Арсланов әлеге изге, истәлекле урынны күз карасы кебек кадерләп, тәрбияләп тора. Җиңү бәйрәмендә дә һәйкәл тирәсен матурлап, тәртипләп куйган иде ул. 9 Майда Карачка кайткан авылдашлар белән бик матур бәйрәм оештырдылар.
(«Актаныш-информ»)

tatarstan.ru

**Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә волейбол буенча унберенче тапкыр Россия чемпионы исеменә лаек булган «Зенит-Казан» ир-атлар волейбол клубын тәбрикләде. Рәис билгеләп үткәнчә, зенитчылар ярдәме белән Татарстанда волейбол зур үсеш алды һәм бүген иң киң таралган, массакүләм спорт төрләренең берсе булып тора. Команда уенчылары исә – яшь волейболчылар өчен чын үрнәк. «Сезнең уңышларыгыз ул – бөтен коллективның тырышлыгы нәтиҗәсе. Команда җитәкчелегенә, уенчыларга һәм Алексей Вербов җитәкчелегендәге тренерлар составына олы рәхмәтемне җиткерәм. Республика Волейбол федерациясенең һәм клубның иганәчесе булган «Газпром» компаниясенә дә рәхмәт», – диде Рөстәм Миңнеханов.**

# ТӨЗЕК ЙОРТТА ЯШИСЕҢ КИЛСӘ

**Белеп тотасы. Күпфатирлы йортларны төзекләндерү өчен халыктан җыелган акчаны үз мәнфәгатьләрендә тоткан җитәкчеләргә җинаять җаваплылыгы каралган. Кыскасы, ул акчага бәйрәм ясарга ярамый!**

Ай саен капиталь төзекләндерүгә дип акча түләп барган кеше үзенә тиешлене аламы? Гомумән, яшәгән йортыбызның яңаруын озак көтәсеме? Төзекләндерүне беренче чиратта кемнәргә ясыйлар? Министрлар Кабинетында узган очрашуда әнә шул хакта сөйләштеләр.

Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллов әйтүенчә, быел Татарстанда 44 республика һәм федераль программа тормышка ашырылачак. Моның өчен 54 млрд 354 миллион сум акча тотылачак. Әлеге программа кысасында төзелеш тармагына караган 3495 объект та бар.

– Быел Татарстанда 751 күпфатирлы йорт капиталь төзекләнделәчәк. Капиталь төзекләндерү өчен ел саен 6 млрд сум акча тотыла. Бу акчаның 60 проценты – милекчеләрнеке, 20 проценты – дәүләт бюджетыннан, тагын 20се – район хакимияте акчасы, – ди министр.

**11685 шуның кадәр**

**2008–2022** елларда **52,33** миллион квадрат метр мәйданда шуның кадәр күпфатирлы йорт төзекләндерелгән. Бу йортларда **2** миллионнан артык кеше яши. Шушы вакыт эчендә капиталь төзекләндерү өчен **83** млрд **177** миллион сум акча тотылган.

Татарстанда капиталь төзекләндерү программасы 2008 елдан бирле эшли. Татарстан бу юнәлештә дә беренчеләрдән була. Шул елны милекчеләрдән җыелган акча Республиканың капиталь төзекләндерү фондындагы махсус казна счетына күчә башлый. Бүген Татарстанда 2043 елга кадәр төзекләндерү программасы кабул ителгән инде.

– Әлеге күпьеллык программага башта 15378 йорт кергән иде. Хәзер инде аларның саны, артып, 17423кә әйләнде. Программада республиканың һәр районы катнаша. Төзекләндерүгә 6 төрле эш керә. Болар – түбәне төзәтү, йортның фасадын яңарту, йорт эчендәге инженер системаларын алыштыру (салкын, кайнар су, җылылык, электр, подвал, газ, канализация), подвалдагы эшләр, фундаментны ныгыту һәм яңа лифт кую. Быелның 1 мартыннан йортта яшәүчеләр үзләренә кирәкләрәк хезмәтне сайлый ала. Кемдер сөлге киптерү торбасын яңарта, кемдер радиаторларны алыштыруны сорый. Подвалга һава торышын көйләүче төймәләр куйдыртучы милекчеләр бар, – ди министр. Сүз уңаеннан, быел 257 лифт яңартылачак.

Апас районында эшләр ахырына якынлашкан инде. Барлык төзекләнделәчәк йортларның 99 процентында эш беткән. Күп җирләрдә эшнең яртысын тәгәлләгәннәр. Ә менә республиканың өч районы – Кайбыч, Чирмешән, Әлки быел бу программада катнашмаган. Белгечләр сәбәбен акча җитмәүдән күрә. Баксаң, районнарның күбесендә бер ел акча туплап, аннан соң зуррак эшләр башкаралар икән.

*Әлеге исемлеккә ничек эләгергә соң? Моның өчен милекчеләр, җыелыш җыеп, тавыш бирергә һәм беркетмә тутырырга тиеш. Идарәче оешма ул беркетмәне район хакимиятенә тапшыра. Министр әйтүенчә, төзекләндерү таләп ителүче йортларга белгечләр дә елга ике тапкыр чыгып, күзәтү ясый икән.*

Төзекләндерү – бер хәл. Халыкны, йортны тышкы яктан матурлагач, аның подъездларының җимерек калуы да борчый. Баксаң, подъезд эче 5 ел саен төзекләнделеп торырга тиеш икән. Ә менә йортны яңартып та, хилафлыклар килеп чыкса, су басса, җимерелсә, бу очракта Татарстанның торак инспекциясенең техник күзәтү бүлегенә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Сүз башым акчага бәйле булган кебек, инде ахырда да халыкның капиталь төзекләндерү өчен күпме акча түләргә тиешлеген искәртеп үтәсем килә. Татарстанда әлеге хезмәт өчен фатирның бер квадрат метрына 6 сум 95 тиен түләнә. Шуны фатирның гомуми күләменә тапкырларга кирәк. Мин исәпләп карадым: безнең идарәче оешма алдаламый икән. Сез дә санап карагыз. Иң мөһиме – гомер буе түләгән акча юкка чыкмасын, аның игелеген күреп, матурланган йортларда яшәсәк иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# КОНОПЛЕВ ЮРИЙ ГЕННАДЬЕВИЧ

**(06.12.1939–05.05.2023)**

Татарстан Республикасы җәмгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Элекке В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты ректоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, профессор Коноплев Юрий Геннадьевич 5 май көнне 84 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Юрий Коноплев 1939 елның 6 декабрендә Казан шәһәрендә туган. Хезмәт эшчәнлеген 1962 елда В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының физика-математика факультетын тәмамлаганнан соң университетта ныклылык лабораториясе инженеры вазыйфасында башлап җибәргән. Соңрак теоретик механика кафедрасына җитәкчелек иткән, деформацияләнүче каты җисем механикасына һәм сыеклык, газ, плазма механикасына бәйле докторлык диссертацияләрен яклау буенча совет рәисе, КДУның халыкара элемтәләр буенча проректоры вазыйфаларында хезмәт куйган.

1990 елда В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты ректоры итеп билгеләнеп, 11 ел дәвамында югары уку йортына җитәкчелек итте. Ул үзгәртеп корудан соңгы болгавыр чорда вузның фәнни-мәгариф һәм тәрбия мөмкинлекләрен саклап кына калмыйча, университетның статусын күтәреп, алга таба үсешен дә тәэмин итте.

Юрий Коноплев бөтен гомерен фәнгә, югары белем бирүгә багышлады. Ул – 180нән артыграк фәнни язма, хисап һәм монографияләр авторы. Фәнни хезмәтләре деформацияләнүче каты җисемнәр һәм конструкцияләр, статик һәм динамик тотрыклылык, тышчалар һәм пластиналар тирбәнешләрен өйрәнүгә багышланган. Аның тарафыннан үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәләре яңа техника конструкцияләрен эшләүдә, технологик җиһазлар һәм корылмалар ремонтлауда фәнни-тикшеренү институтларында, проект-конструкторлык бюроларында бүгенгәчә файдаланылып килә.

Юрий Геннадьевич соңгы елларда, Казан (Идел буе) федераль университетының мактаулы профессоры буларак, Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институтының теоретик механика кафедрасында укытты, яшь галимнәрнең остазы булды.

Юрий Коноплевның күп еллар буе нәтиҗәле хезмәте югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе», «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты, СССР Халык мәгарифе буенча дәүләт комитетының, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының Мактау грамоталары.

Ул үзенең хезмәт сөючәнлеге, бик зур оптимизм рухына ия булуы, кешелеклелеге, ихтирамлы мөнәсәбәте белән коллегалары һәм республика җәмгатьчелеге алдында зур абруй, ихтирам-хөрмәт казанды.

Юрий Геннадьевич Коноплевның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

Р.Н. Миңнеханов, М.Ш. Шәймиев, Ф.Х. Мөхәммәтшин, А.В. Песошин, Ә.Ә. Сәфәров, И.Г. Һадиуллин, И.Р. Метшин, М.Х. Сәлахов, Л.Р. Сафин, А.А. Калачев

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы Актаныш районының Күҗәкә авылыннан биш бала анасы **Фазлыева** Илсөяр Әбүдәр кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Ленино-Кокушкино урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләре: география укытучысы **Әхмәтҗанов** Зефир Заһид улына, физик культура укытучысы **Чукуров** Алексей Ивановичка, директор **Шаронова** Ирина Викторовнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

**Язучы сүзе**

# САЗЛЫК ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Марат КӘБИРОВ

Безнең телдә «уңышка омтылу», «җиңүгә омтылу» кебегрәк матур сүзләр бар. Шуны ишеткәндә, мин гел күсе өстенә сикерергә әзерләнеп беткән песине күз алдына китерәм. Әгәр «омтылыш» төшенчәсенең рәсемен ясарга кирәк булса, нәкъ әнә шул мәчене төшерергә туры килер сыман. Җиргә сеңеп бетә язып төбәлгән ул бер ноктага, хәрәкәтсез, ара-тирә мыеклары яки колак очлары гына дертләп куя, талгын гына арт якларын уйнатып ала һәм кинәт… Юк, ташланмый, укталып кына куя – омтыла. Омтыла да тыелып кала. Безнең уңышка омтылуыбыз да, бәлки, шундыйрак сурәттәдер. Омтылышның күплеге отышлы.

Адәм баласының омтылышы аз гына бүтәнчәрәк бугай. Без, уңышны тапкач, бер ноктага гына төбәлеп, сәгатьләр буена чыдап утыра алмыйбыз. Бөтен игътибарыбызны шул табышка юнәлтәсе урында, без тирә-ягыбызга каранабыз – зуррагы, җайлырагы юкмы?.. Күз күремендә андый нәрсә шәйләнмәсә, арырак барып карыйбыз. Тирә-яктан әйләнеп киләбез. Ә ул арада инде теге табышыбыз табанын ялтыраткан була һәм без тагын уңышның яңасын эзләп китәбез. Табабыз. Омтылышны эшкә җигәбез. Әмма күзләребез тагын тирә-юньне айкый. Ә бераз гына арырак бер адәм үз табышын сагалап утыра. Аныкы зуррак та, матуррак та сыман тоела. Үзебез тапканы инде бөтенләй мәгънәсен җуя. Һәм без, мамонтка ташланган ата-бабаларыбыз шикелле шау-шу кубарып, үз табышыбызга ташланабыз. Тота алмыйбыз. Ләкин күңелдә шатлык бии, чөнки безнең максат үз табышыбызны эләктерү түгел, ә теге адәмнекен өркетү иде. Без өркеттек. Әйе, үзебезнекен югалттык. Тик ул бик зур табыш түгел иде. Шуңа безнең югалту да зур түгел. Ә күршенеке зур иде. Һәм ул тота алмады.

Шул рәвешле, адәм баласының омтылышы берьюлы әллә ничә юнәлештә эшли. Ул бер үк вакытта әллә ничә тарафка омтыла. Берьюлы әллә ничә табышны күрә. Чагыштырып карый. «Кайсын эләктерсәм, ничегрәк булыр икән?» – дип исәп-хисап йөртә. Һәм берсен дә эләктерә алмый. Тота алмаулары ешрак кабатланган саен, күңеле төшә, үзен булдыксыз итеп тоя. Депрессиягә бирелә, яшисе килми башлый. Бер карасаң, шулай булырга тиеш инде. Хәтта песи белән генә чагыштырсаң да, әчпошыргыч күренеш килеп чыга бит. Тирә-ягында берсеннән-берсе матуррак, симезрәк күселәр уйнаклый, ә ул берсен дә тота алмый. Әле берсенә, әле икенчесенә кызыгып йөри, шуларны абалаган күрше песиләреннән көнләшә. Омтылышы җитми тегенең. Омтылышы булган хәлдә дә ул әйбәт председатель рәвешендә түгел.

Төшенкелек турында уйлаганда, гел бер мәзәк искә төшә. Кемнәндер ишеттемме, кайдандыр укыдыммы инде аны, хәтерләмим. Авторы булса, аңа рәхмәт. Ул хәл менә мондыйрак. Берәү урманнан узып бара икән, сазлыкка килеп чыккан. Сазлык эчендә бер кеше биленнән баткан да елап утыра, имеш. Төпкә дә төшеп китми бу, чыгарга дип тә укталмый, елап тик утыра. «Мине беркем дә яратмый, коткарырга беркем дә килми, берәү дә хәлемне белешми…» – дип мышкылдый инде. Узгынчы беркадәр карап тора да моны бик нык кызгана, керфегенә сыгылып чыккан күз яшьләрен сөртеп ала да, чишенеп, моның янына кереп утыра һәм аның ялгызлыгын һәм аяныч хәлен уртаклашырга теләп, кушылып еларга тотына: «Безне беркем дә яратмый, коткарырга беркем дә килми, берәү дә хәлебезне белешми…»

Әгәр кешегә чын ярдәм күрсәтмисең, аны авыр хәленнән чыгарырга омтылмыйсың икән, һәрбер «кайгы уртаклашу», юату ясалмага әверелә. Теге узгынчы да сазлыктагы адәмне тартып чыгарырга, аңа таякмы-баумы сузарга, һич югында үгетләп, тиргәп яки камчылап, аны хәрәкәткә этәрергә тиеш иде бит инде. Ә ул үзе аның янына кереп еларга тотынган. Чөнки бу күпкә җиңелрәк. Үз булдыксызлыгыңнан котылуга караганда аңа аклау эзләү күпкә җайлырак, чөнки тормышның һәм заманның миллионлаган җитешсезлеген табып була, шул җитешсезлекләрне тапкан исәпсез-сансыз кеше синең теләктәшеңә әверелә, ә бу үзеңне гаделсезлекләр белән көрәшүче гаярь зат итеп тою мөмкинлеге бирә. Кызык инде, бер карасаң, көләсе генә килми.

Омтылышны ныгыту өчен максатның төгәллеге мөһимдер, бәлки. Шунда омтылыш та көчлерәк, гамәлләр дә исәпләнгәнрәк була аладыр. Күсе ауларга җыенган мәче омтылышы шикеллерәк. Ә болай…

Тирә-яктан төрле авазлар ишетелә… «Милләт бетә!.. Телебез бетә!.. Халкыбыз юкка чыга…» Әллә, чынлап та, сазлыкка баткан кеше авазлары алар, әллә аның янына кереп утырып елашкан узгынчыныкы, аңламассың. Бәлки, икесе дә. Без кычкырып еларга өйрәндек бит инде. Сазлык үзебезнеке…

# ТАРИХНЫҢ БОРЫЛГАН ТӨШЕНДӘ

Без, россиялеләр, май ялларын уздырганда, дөньякүләм вакыйгалар үзләренең кайнау ноктасына таба якынлашты. Аларга берничә генә сүз белән бәя биреп була: барысы да катлаулы. Вакыйгалар үсешен барыннан да бигрәк икътисадый вазгыять билгели, әлбәттә. Икътисадта исә сөендерерлек нәрсәләр юк диярлек. Американың дәүләт бурычы вакытыннан алда түшәмгә килеп терәлде. Андый вакытта американнар түшәмне күтәрәләр һәм бу дефолттан вакытлыча коткара. Әмма гел күтәреп торгач, түшәм шулкадәр биегәйде: галәмгә чыгып китәргә җыена. Күтәрмичә дә калып булмый, чөнки АКШ дефолты дөнья икътисадының астын өскә китерәчәк. Без ял иткәндә, Байден, конгрессменнар белән түшәм мәсьәләсендә килешү өчен, беренче очрашуын үткәрде. Очрашу нәтиҗәсез тәгәлләнде. «Мин, – диде конгрессмен Маккарти (Байден оппонентларының берсе, түшәмне күтәрүгә каршы чыгыш ясый), — бернинди яңа хәрәкәт тә күрмәдем». Ягъни Байден вәгъдәләре АКШ өчен канун әвәләүчеләрне ышандыра алмаган. Байден үзе: «Дефолт АКШ икътисады өчен җимергеч булачак», – дип әйтү белән чикләнде. Без фаразлый алабыз инде, билгеле: ялындырып булса да конгрессменнар түшәмне күтәрергә ризалык бирерләр. Әмма ул проблеманы хәл итмәс, артка гына чигерер. Бурычлар проблемасы бер Америкада һәм Европада гына түгел, башка илләрдә дә кискен тора. Кытай әҗәте быел беренче кварталда, аннан алдагы квартал белән чагыштырганда, 7,7 процентка сикерде. Бу – соңгы өч елдагы рекордлы күрсәткеч. Шанхай фонд биржасының элекке җитәкчесе Чжу Цунзю кулга алынды. Әмма финанс кыры репрессияләр белән генә сәламәтләнерлек түгел. Үткән атнада Sentage Holdings дип аталган кытай банкының акцияләре 40 процентка түбәнгә очтылар. Кытайның иң эре банклары рентабельлелекнең кимүеннән зарланалар. Кытай икътисадын упкынга очырачак күчемсез милек базарында хәлләр 2024 елда кискенләшер, дип фаразлана.

Европа банклары торак кредиты бирү күрсәткеченең үз тарихындагы иң начар хәлдә булуын игълан иттеләр. Хәл Бөек финанс кризисы елларындагыдан да начаррак. Согуд Гарәбстаны – углеводород бәяләре дулкынында акча коенган ил – быел беренче кварталда бюджетының дефицитлы булуын белдерде. Дефицит зур түгел, 770 миллион доллар гына, әмма аның пәйда булуы гарәпләрнең якын киләчәктә «кара алтын» чыгаруны киметүдән туктаячакларын вәгъдә итә.

Бер генә нәтиҗә ясый алабыз: кешелек тарихы зур борылыш мизгеленә кереп бара. Елганың борылган төшендә иң хәтәр урын икәнен һәркем белә. Тарих өчен дә шулай ул: вакыйгалар тизләнә, дәүләтләр һәм халыклар бәйдән ычкынган сал агачлары кебек бер-берсе белән бәрелешә башлый. Без аны Россия – Украина конфликты мисалында үз җилкәбездә татыйбыз. Ул конфликт безне матди яктан да, рухи яктан да изә.

Зур дефолт алдында торган илләр саны арта һәм менә шуларда эчке каршылыклар яшен булып яшьни башлый да инде. 9 май кичендә Пакьстан яңадан дөрләде. Атом-төш державасы булган бу ил болай да мөнәсәбәтләрне үзара бәрелешләр, хәрби түнтәрелешләр ярдәмендә ачыкларга яратуы белән аерылып тора. Бер ел элек ил тарихында беренче тапкыр, ышанычсызлык белдереп, Премьер-министр Имран Ханны идарәдән читләштерделәр. Үз сәясәтенең төп юнәлеше дип коррупциягә каршы көрәшне игълан иткән Премьер-министр халык мәхәббәтен яулап өлгергән иде. Ул идарә иткәндә, Пакьстанның Россия һәм Кытай белән мөнәсәбәтләре яхшырды, Америка белән, киресенчә, начарайды. Күп халык яши торган ул Азия иле әле дә Россиягә «дус илләр» исемлегендә, Мәскәү белән «кара алтын» сатып алу турында килешү төзеп ята. Арзан бәягә, билгеле. Илнең финанс хәле бик начар. Гамәлдәге хөкүмәткә Согуд Гарәбстаны күптән түгел генә финанс ярдәме күрсәтеп карады, ләкин бирелгән акча Пакьстан өчен бик аз. Җитмәсә, элекке Премьер-министрның популярлыгы яңа хөкүмәтнең эшчәнлегенә тап төшерә. Аны берничә тапкыр кулга алып, сәясәт кырыннан чыгарырга тырышып карадылар. Халык яклап калды. Имран Хан үзе дә йоклап ятмады, кискен сәяси көрәш алып барды. 2022 елның көзендә «озак протест маршы» оештырып, Исламабадка барганда, полицейскийлар, атып, аның аягын яраладылар. Рәсми хакимиятләр популяр лидерны террорга каршы закон нигезендә гаепләргә тырышып карадылар. Һәм, ниһаять, чит ил сәясәтчеләреннән бүләкләр алуда, шул бүләкләр белән махинация оештырып, 600 мең доллар акча эшләүдә гаепләделәр. Имран Хан, 9 май көнне үзен яклауны сорап, Исламабадның Югары судына килде һәм шунда кулга алынды. Хәрби формированиеләрнең Югары судка бәреп керүе үзе бер сугыш кырын хәтерләтте. Авторда аның видеосы бар. Кулга алу белән эш тукталмады. Халык ярсуы илне зур бәрелеш кырына әйләндерде. Баш күтәрүчеләр Банну хәрби шәһәрчегенә ут төртте. Лахор, Пешевар кебек зур шәһәрләрдә дә хәрби лагерьларның штаб-квартираларын ялкын ялмады. Чакдар форты фетнәчеләр тарафыннан яулап алынды. Абботтабад шәһәрендәге полкның штаб-квартирасы да һөҗүмгә дучар булды. Аботтобад – Усама бен Ладен үтерелгән шәһәр. Без алган соңгы хәбәрләрдә армия һәм ил җитәкчелегенең чит илгә качуы әйтелә. Соңгы хәбәрләрнең дөресме-юкмы икәнен без әлегә әйтә алмыйбыз. Пакьстанда бер Премьер-министр да срогы беткәнче утыра алмый диярлек. Илдәге авыр икътисад шартларында (үткән елгы газ кризисын ил бик авыр кичерде) инде традициягә әйләнгән бунтның яңадан мәйданга чыгуы гаҗәп тә түгел кебек. Ләкин бу барыбер вазгыятьнең төп этәргече якынлашып килүче финанс коллапсы булуын дәлилли.

Планетадагы барлык фетнәләрнең дә асылында процент капиталына нигезләнгән идеология ята. Барлык байлыкларны аз санлы олигархлар файдасына бүлешү технологиясе буларак эшләнгән финанс системасы халыкларны неоколониализм рәвешендә кабалага төшерә.

Соңгы көннәрдә зур хәрби бәрелеш һәм фетнә мәйданына әверелгән Суданны гына алып карыйк. Халкының 40 проценты хәерчелек чигеннән түбәндәрәк яши торган әлеге Африка иле гаҗәп зур байлыклар өстендә утыра. Капиталистик державаларның «бүлгәлә һәм хакимлек ит» дигән сәясәте бик нечкә итеп үткәрелү сәбәпле, бөлгенлектә яши. Илдә бар кеше дә фәкыйрь түгел ләкин. Соңгы көннәр фетнәсенең башында торучы Тиз хәрәкәт итү көчләре командиры Хәмәдтинең алтын белән сәүдә итүдән кергән 7 миллиард доллар акчасы Берләшкән Гарәп Әмирлекләре банкында ята, диләр. Бу гаҗәп түгел, чөнки ил алтынга һәм нефтькә бай, башка металларның мул ятмалары да җитәрлек. Бүген сугышучы ике капма-каршы көчнең берсе – нефть ятмаларын, икенчесе алтын приискларын үз кулында тота. Әмма илнең төп байлыгы – сөрүлек җирләре. Җир шарындагы иң яхшы сөрүлек җирләре шунда. Халыкара оешмалар мәгълүматларына караганда, сөрүлек җирләренең ике проценты гына эшкәртелә. Калган җирләрне эшкәртүгә аяк чалучы махсус план бар, дип әйтәләр. Ул план дөньяның финанс акулалары тарафыннан эшләнгән. Илнең барлык җирләре дә эшкәртелсә, диләр белгечләр, бер сезон уңышы 800 миллион кешене туйдырырга җитәр иде. Суданда 30–40 миллион тирәсе кеше яши. Шулардан чыгып нәтиҗә ясыйк: планетадагы авыр вазгыять кемнәр тарафыннан тудырыла? Халыклар интуитив рәвештә үзләренең талануларын тоялар һәм без югарыда күзәткән фаҗигале хәлләргә старт бирелә. Фетнәләр проблеманы хәл итми, кискенләштерә генә, әмма тарих үзенең кискен борылыш мизгеленә якынлаша. Монысы хак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

# ЙОЛДЫЗНЫ КҮТӘРИК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

**Борынгы авыл**

«Урал арты татарлары» җәмгыяте рәисе Марат Юнысов сүзләренчә, Йолдыз-Эчкен авылына 1525 елда нигез салынган.

– Бик затлы, бай, борынгы татар авылы иде Йолдыз. Нарат урманының уртасында урнашкан бик матур авыл. Халкы тырыш, эшмәкәрләр дә, фермерлар да бик күп. Бөтен карашыбыз аларга төбәлгән, үрнәк иде ул, чөнки татарның элитасы шунда яши. Ике, өч катлы йортлары, җитеш, мул тормыш алып барулары белән данлыклы иде, – ди ул.

Ни кызганыч, ут шундый зур тарихлы, гөрләп яшәп яткан авылны да аямый.

– Янгын авылга күршедәге Себерке авылыннан өске яклап, агач башлары буенча килде. Төп авырлык шунда иде. Янгын астан килгән очракта, көрәшү мөмкинлеге бар иде, саклану чаралары да күрелгән иде югыйсә. Җил дә бик көчле булды. Юнәлешен өч тапкыр үзгәрткән җилнең тизлеге секундына 40 метрга кадәр җитте. Барысы да бик тиз булды. Эвакуация өчен халыкка 15 минут вакыт бирелде. Кайберәүләр хәтта документларын да алырга өлгермәгән, – ди Марат Юнысов.

Йолдыз – танылган опера җырчысы Ярамир Низаметдиновның туып-үскән авылы. Анда аның әти-әнисе, туганнары, дуслары яши. Бәхеткә, җырчының якыннары яшәгән урамны саклап кала алганнар. Шул исәптән Ярамирның туган нигезен дә.

– Күрше авылдагы көчле янгын турында иң элек әнием шалтыратып әйтте. 20 минуттан соң инде үзләренең дә авылдан чыгып китүләрен язып җибәрде. Без сеңлем белән ахырга кадәр яхшыга өметләндек. Ләкин, кызганыч, бу кайгы безне дә читләтеп узмады.

Сакланып калган бердәнбер урамда агач мәчет тә бар. Шулай ук яңа таш мәчеткә дә ялкын телләре үрмәләмәгән. Гомумән, авыл халкы әйтүенчә, могҗиза булырдай күренешләр шактый.

– Без моны Аллаһы Тәгаләнең хикмәте дип кабул иттек. Тулысы белән янган урамда бер йорт ялгызы гына утырып калган. Аннан соң йорт-җир, барлык корылма янып көлгә әйләнгән ишегалдында ут «ГАЗель» машинасына гына кагылмаган, – ди алар.

*Уралда янгыннар белән вазгыять узган атнада катлауланды. Атна башына булган мәгълүматлар буенча, Курган өлкәсендә 13 урман янган, Свердловск өлкәсендә дә 70кә якын җиргә ут капкан. Соңгы мәгълүматлар буенча, Курган өлкәсендә генә дә 21 кешенең һәлак булуы билгеле. Шуларның 7се – Йолдыз авылында.*

**«Бу коточкыч иде»**

Коточкыч төннең шаһиты булган Изольда Сабирова авылдашлары белән бергә кичергәннәрне тыныч күңел белән генә сөйли дә алмый. Бераз сөйли дә, күңеле тулып, туктый алмыйча елый башлый.

– 59 ел яшәп, мондый хәсрәт күргән юк иде, – диде ул. – 7 май көнне бик көчле җил күтәрелде. Күршедә 50 хуҗалыклы Плоское авылы бар иде. Ул ярты сәгать эчендә тулысынча янып бетте. Шуннан соң янгын күршедәге Себерке авылына күчте. Ялкын телләре акрынлап безгә якынлашты. Ул арада авыл төркеменә: «Вазгыять бик җитди. Документларыгызны, кирәк-яракларыгызны җыегыз», – дигән хәбәрләр килә башлады. Күптән түгел генә йөрәгемә операция ясадылар. Яңа тернәкләнеп килә идем, бер минут эчендә барысын да ташлап чыгып китәргә дә теләмәдем. Кичке 5тә ирем эштән кайткач, машинабызга утырып, юлга кузгалдык. Авылдашларны автобусларга утыртып, Шатровск районына таба эвакуацияләделәр. Кая барганны төгәл аңламыйча да барыбыз бер колонна булып хәрәкәт иттек. Юлда да бик авыр булды. Берни күренми, тирә-як ап-ак төтен. Ялкын бөтен дөньяны камап алган иде. Юлда аварияләр дә булды. Без бераз барабыз да туктап торабыз. Арттарак калган ялкын телләре безне тагын куып тота. Бара торгач, Түмән өлкәсенә чыктык. Төн җитте, караңгы төште. Йөрәк кенә урынында түгел. (Елый. – **Авт.**) Төркемгә бер-бер артлы «бу йорт янып бетте», «бу урам юк», «икенчесе дә янып бетте...» дигән хәбәрләр килеп кенә торды. Шунда тормыш иптәшем белән бер-беребезгә караштык та: «Кайтыйк, өебез, авылыбыз ни хәлдә икән...» – дидек. Ут эченнән тагын кайтырга чыктык. Юлда исән калган бер генә нәрсә дә очрамады. Бу коточкыч иде.

«Татар-информ»

**Татарстаннан 20 тонналы фура Йолдыз авылына кузгалды.**

Тоташ ут эчендә калган авылларына кайтып төшә Сабировлар. Полиция хезмәтләре беркемне дә эчкә уздырмый. Тик алар, башка керү юлларын табып, йортлары тирәсенә уза ала.

– Мин йортыбыз ягына карарга да курыктым. Иремнән: «Нәрсә анда?» – дип сорарлык кына көч таптым. «Урамыбыз тора бугай», – ди. Чыннан да, безнең Олы урам гына янгыннан исән калган иде. Урамыбызда иске агач мәчетебез бар иде. Хәтта ул да исән калды, – дип елый Изольда ханым. – Аллаһның безгә күрсәткән рәхим-шәфкате булгандыр инде. Ләкин сөенеп булмый, чөнки, бердән, авыл, авылдашлар өчен борчылсак, икенчедән, бар җирдә дә ут пыскып ята. Урманнар, авыллар яну дәвам итә. (Язманы әзерләгәндә, 1000 кешелек тагын бер татар авылы – Кызылбайны уттан саклауларын хәбәр иттеләр. – **Авт.**) Ул төндә безнең белән бергә эвакуацияләнгән башка ир-атлар да көлгә әйләнгән нигезләренә кайтып баскан иде. Барысы да шок хәлендә һәм аптырашта. 4–5 балалы гаиләләр йортсыз-җирсез калды. Терлекләр, эт һәм песиләр дә күп үлде. Хуҗаларының көлгә әйләнгән нигезләре янында этләрнең әрнеп елап утыруларын күреп, күңел сыкрый.

Соңгы мәгълүматлар буенча, янгында җиде кеше һәлак булган. Өч кеше хастаханәдә дәвалана. Бер кеше хәбәрсез югалган, ләкин Марат Юнысов әйтүенчә, корбаннар саны тагын да күбрәк булуы бар.

Әлегә урман янгыннарының төгәл сәбәпләре билгеле түгел. Саксызлык, битарафлык та булуы мөмкин, диләр. Авыл халкы исә «теракт, махсус яндырган булырга тиешләр» дигән фаразларын да җиткерде. Әлегә тикшерү эшләре бара. Ахыргы нәтиҗә шулардан чыгып билгеле булыр дип көтик.

**Киләчәге нинди?**

Әлеге вакытта авыл халкы янгыннан исән калган мәктәп һәм клуб бинасында яши.

– Янгынның беренче көнендә кешеләр якыннарына киткән иде, икенче көнгә барысы да авылга әйләнеп кайтты. Йортларын кабат торгызмакчы булалар. Милли аксакалларыбыз да авылның таралмавына, кабаттан торгызылуына бик өметләнә. Беренче-икенче көннәрдә барысы да шок хәлендә иде. Әле дә нәрсәдер уйларлык, хәл итәрлек хәлдә түгел алар. Бераз вакыт кирәк булыр, – диде Марат Юнысов.

Ярамир Низаметдинов та туган авылын кабаттан торгызып, элеккеге халәтенә кайтару турында хыяллана һәм булдыра алганча ярдәм итәргә ниятли.

– Мин бу фаҗигане тасвирлап бирер өчен сүзләр таба алмыйм, – ди Ярамир. – Мин – кече ватанымның чын патриоты. Авылымны, аның халкын, йолаларын, диалектын бик яратам. Мин аңа бик рәхмәтле, чөнки бүген ирешкән уңышларымның барысында да аның өлеше зур. Авылның шундый хәлгә калуы – минем өчен зур югалту. Ике көн шок хәлендә йөрдем. Әле җитмәсә, тамашачы каршына спектакль белән чыгарга кирәк. Ничек кенә авыр булса да, сәхнәгә чыгып елмаерга туры килә.

Аның фикеренчә, бу фаҗига артында тирән мәгънә ята.

– Монда бер авыл фаҗигасе генә түгел, милләт фаҗигасе дә бар, – ди ул. – Әгәр татар авыллары бетә икән, татар теле, гореф-гадәтләре, мәдәнияте дә юкка чыгачак. Чөнки аларны зур шәһәрләр түгел, ә менә шундый ерактагы авылларда яшәүчеләр саклый. Бу хәлдә халыкның бер өлеше башка җирләргә, рус авылларына, шәһәрләргә күченеп китәргә мөмкин. Катнаш никахлар булуы да бар. Мин менә шуннан куркам. Аллаһы Тәгалә безгә бу сынауны ни өчендер биргән. Бәлки, ул халыкны берләштерер, кузгатыр өчен кирәк булгандыр?

## Берләшү көче

Безнең халыкның исә кайгыда берләшү сәләте көчле. Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче гади халыкның, эшмәкәрләрнең ярдәм кулы сузуларына Изольда ханым да, Ярамир да кат-кат басым ясады. Марат Юнысов әйтүенчә, әлегә дәүләт янгыннан зыян күргән һәр кешегә 10ар мең сум акча биргән. Йортлары янып бетүчеләргә – 50шәр мең сум, янгында һәлак булучыларның гаиләләренә 1 миллион сум күләмендә акчалата ярдәм каралган.

– Пособие алырга 600 кеше гариза язды. Ләкин бу әлегә тулы исемлек түгел, чөнки кемдер вахта ысулы белән читкә китеп эшли. Исемлек тулылана, – диде ул.

Бөтендөнья татар конгрессы да, янгында зыян күрүчеләргә матди ярдәм җыю өчен, махсус счет ачты. Моннан тыш, штабка алып килгән азык-төлек, киемнәр, гигиена кирәк-ярагы, өй җиһазлары һәм башка әйберләр төялгән гуманитар ярдәм белән 20 тонналы фура Йолдыз авылына кузгалды.

– Әлеге вакытта без ачкан махсус счетка 2 млн сумнан артык акча җыелды. Ярдәм җыю дәвам итә, – диде Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Марс Тукаев. – Башка оешмалар, төбәкләр дә ярдәмгә кушылды, счетлар ачылды. Шуны әйтәсем килә: хәзергә көндәлек кием-салым күп җыелды, әлегә җитә. Ә менә **төзелеш материалларына, хуҗалыкта кирәкле коралларга, эшләр өчен махсус киемнәргә, электрогенераторларга, савыт-сабага, урын-җиргә ихтыяҗ бар.** Моңа кадәр без һәрвакыт берләшә, ярдәмләшә алдык. Киләчәктә тә авыр хәлдә калган милләттәшләребезгә булдыра алганча булыша алсак иде.

**ЯРДӘМ ИТҮ ӨЧЕН**

**БАНК РЕКВИЗИТЛАРЫ:**
Отделение «Банк Татарстан» № 8610 ПАО Сбербанк г. Казань
р/с 40703810162020100015
БИК 049205603
к/с 30101810600000000603
**Внимание!** Обязательно для заполнения «Пожертвование для оказания помощи пострадавшим от стихийного бедствия жителям с. Юлдус (Шадринский МО Курганской области). Без налога (НДС)»

Сәрия МИФТАХОВА

# ТУГАН ЯГЫ КИРӘК КЕШЕГӘ

**«Ел саен диярлек мин авылыма кайтып киләм. Кайтам да үземнең балачак, үсмер чак эзеннән, бергә уйнап үскән иптәшләрем, туганнарым, яраткан кешеләрем эзеннән йөрим», – дип язган Гомәр Бәширов. Без исә әдипнең йөргән сукмакларын урап, Җидегән чишмә суын эчеп, Арча районындагы Яңасала авылының яшәеше белән танышып кайттык.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

**Кабак тавыннан менгәндә, Җидегән чишмә уң якта кала. Сүз уңаеннан, элек авыл аша олы юл үткән. Бер урыс бае кабак тоткан. Шуннан соң татарлар аны татарчалаштырып, Кабак тавы дип йөртә башлаган.**
**Авылда җиде чишмә бар. Җидегән, Бәллүр, Сапый, Гафур, Кабак тавы, Павал чишмәсе – барысы да бер тау битеннән агып чыга. Изгеләр чишмәсе – иске авыл урнашкан урында. Җидегән чишмә җиде улаклы түгел. Г. Бәширов нигезенең бакча башыннан агып чыга ул. Барысының да суы тәмле, халык бик яратып эчә икән.**

### Җаны бар...

Авылга кергәнче, табигатен күзәттек. Гомәр ага язганча, чыннан да, яшел бишек! Әллә яз иртәрәк килгәнгәме, агачларның ябалдашлары бермә-бер зуррак һәм ул йомшак зур яшел бүрекне хәтерләтә кебек. Яңасалага җиткәндә исә әдипнең «Кечкенәдән суын эчеп үскән авылым чишмәләре, кайда гына булсам да, исемнән чыкмады» дигән сүзләре язылган. Шуннан соң да бу чишмәләрне күрмичә кайтып була димени? Бигрәк тә Җидегән чишмәне.

Без килгәндә, төзүчеләрнең күперне яңарткан чагы иде. Кайбер урамнарда экскаватор җир казый. Су кертәләр икән. Авылга керүгә, ниндидер бер җанлылык сизелде. Хезмәттәшләрем дә: «Авылның рухы бар», – диеште. Менә шунысы кыйммәт тә инде аның.

Яңа Салада бүген 111 хуҗалык, 249 кеше исәпләнә. Татарлар да, керәшеннәр дә дус яши. Халкы тырыш, сабыр холыклы. Артуга бармаса да, кеше саны әллә ни кимеми. Мәктәбе, бакчасы, фельдшер-акушерлык пункты, музей, китапханәсе, клубы эшләп тора. Авылда яшәгәне дә, йөреп эшләүчесе дә бар.

Авыл җирлеге башлыгы Айрат Сафин әйтүенчә, авылның йөзе үзгәрә бара. Соң, авылымнан да кадерле җир юк, дип Яңасаласына кайткан. Авылны бер йодрыкка туплап тотучы ул.

### Нигезендә – әдәби бакча

Китапханәче, музей директоры Фәридә Борһанова әйтүенчә, дүрт ел элек Гомәр аганың нигезендә әдәби бакча ачылган.

– Балалар әдипне онытмый. Исләренә гел төшереп торабыз. Арча районы укучылары экскурсиягә килә. Күрше-тирә районнардан да килүчеләр бар. Оныклары да бабалары турында кызыксынып тора. Авылдашларның шигырь кичәләрен дә монда үткәрәбез, – ди ул.

Мәктәптә Гомәр Бәшировның музее бар. Монда аның язу өстәле, урындыгы, портфеле, язу машинасы, каләме, сугыш чорында корреспондент булып эшләгәндәге фотоаппараты һәм башка экспонатлар урын алган.

Гомәр Бәширов әсәрләрендәге геройлар арасында үз авылы кешеләре дә бармы? «Намус» романындагы Нәфисә образының прототибы шушы авылда яшәгән, бригадир Васфикамал апа икән. Бу хакта улы – Арча педагогия көллиятенең өстәмә белем бирү педагогы Фәрит Минхәеровтан сораштык.

> Җир өстенә барып җиткәч, әти, уртага кереп, бер йомарлам туфрак казып алды да аның җылылыгын чамаларга кереште. Ул аны әле бер кулында, әле икенчесендә кысып карады. Аннары, җиңен сызганып, беләгенә куйды, борынына якын китереп иснәп алды. Ул туфракны шундый ипләп, күзләрен йома төшеп, шундый ихлас күңел белән тәмле итеп иснәде, аның бераз җылымсарак төче исе хәтта минем борыныма да килеп кергәндәй тойдым.
>
> (Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәреннән)

Йортлар төзек, көннән-көн матурая. Урамнарга таш җәю дәвам итә. Буш торган йортлар берничә генә икән. 25–30 ел элек хуҗалыкларның һәркайсы ишегалдында кое казыткан булган. Хәзер «Чиста су» программасы буенча йортларга су кертү тәмамланып килә.

– Фермалар бетте. 12 ел элек мәктәп кыскартылып, башлангычка калдырылды. Анда җиде бала укый. Эш, мәктәп булмагач, яшьләр читкә китте, – ди Айрат Сафин.

Заманасында үзенә дә шәһәрдән яхшы эш тәкъдим иткәннәр. Бер көннән

– Әни 79 яшендә вафат булды. Гомәр абый сугыштан соң Яңасалага кайткач, Васфи, кил әле, дип, сугыш вакытында кырдагы хәлләрне, җирне эшкәртү, чәчү турында сораштырган, – ди Фәрит Минхәеров. – Әни – гаиләдә олы бала. Шуңа күрә аңа өлкәннәр белән берләттән эшләргә туры килгән. Әтисе мәктәпкә укырга җибәрмәгән. Хыялы белем алу булган. Сугышка кадәр Казанда мех фабрикасында эшләгән. Менә шул вакытта ике ел кичке мәктәптә укыган. Сугыш башланыр алдыннан авылга кайткан. Аны кыр бригадиры итеп билгелиләр. Ирләр – фронтта, әни колхозның җигелмәгән айгырларын кулга ияләштергән. Хезмәте өчен медаль белән бүләкләнгән.

Яңасалада Гомәр Бәшировның эзләре әле дә саклана.

### Хатлар

Оркыя апа Мөхәммәтҗановага – 74 яшь. Заманында авыл советы рәисе булып эшләгән.

– 1969 елда Яңасалага Балтач якларыннан килен булып килдем. Авыл советында эшли башладым. Гомәр ага белән шул елларда аралаша башладык. Ул вакытта Казанда яши иде ул, авылга кайтып йөрде. Аның белән хатлар язышa идек. Мәктәпкә дә, авыл халкына да аерым яза иде. «Нинди ярдәм кирәк?» – дип сорап торды. Яңа мәктәп ачарга булышты. Мәктәп тормышы, укытучылар белән кызыксына иде. Очрашуларда авылның үткәне белән ул вакыттагысын чагыштыра иде, – ди Оркыя апа.

Нурания апа Сафинага – 81 яшь. Хисапчы булып эшләгән Нурания апа Гомәр Бәширов романнарын укып үскән, аңа хат та язганы бар икән.

– Әнием яшьли үлде. Әтиебез Гарәфи Гомәр аганың туганы Хәерниса әби белән бергә яши башлады. Әти миннән Гомәр агага хат яздыртты», – дип истәлекләре белән уртаклашты Нурания апа.

### Меңдең дә атландың түгел...

Айрат Сафин инглиз токымлы чабышкылар тота. «Чыгымлы, әмма күңелгә ял бирә торган шөгыль», – ди ул. 10 яшьтә үк Сабантуйларда чаба башлаган ул. Хәзер дә республика, илкүләм ярышларда катнаша. Уллары да әтиләреннән калышмый.

– Атка меңдең дә атландың гына түгел. Аны берничек тә гараждагы мотоцикл, велосипед яки машина белән чагыштырып булмый. Абзардан атланып чыгып китү өчен, аны ярты сәгать әзерләргә, яхшылап чистартырга кирәк. Тир эзе калмаска тиеш, ул тәнен кырырга мөмкин, – ди хуҗа.

### Җылы саклаучылар

Авылдан башка тормышларын күз алдына китерә алмаган ир-егетләр белән дә күрештек.

Идеал Мөхәммәтҗанов Арчадагы кирпеч заводында эшли. Авыл арасы – 25 чакрым. Буш вакытында тәрәзә йөзлекләре ясарга да өлгерә.

Рәйдә һәм Геннадий Туюровлар 2010 елдан бирле терлекчелек, игенчелек белән шөгыльләнә. Тик фермер булып теркәлмәгәннәр. Геннадий Биектау, Арча, Саба, Теләче районнарында газ кертә. Шул ук вакытта авылда 160лап гектар җире, 30лап мөгезле эре терлеге дә бар. Хатыны – уң кулы.

– Ел саен баш санын арттырып бара идек. Арттырып булмый хәзер. Сөт бәясе төште. Хәзер ул – 21 сум. Кышкы чор белән чагыштырганда, айга 40 мең сум акча югалтабыз. Кичәге план бүгенгә ярамый. Авыл хуҗалыгына һаман аяк чалалар, – ди 49 яшьлек Геннадий.

Авыл халкына печәнен, ашлыгын түбән бәядән бирә ул. Моңа кадәр трактор белән авыл урамнарын кардан чистарткан. Үзе яшәгән урамга таш җәяргә булышкан.

– Авыл яклы инде мин. Яшьләр китмәсен иде, дим. Буш урыннар күп, йорт урыннары алсыннар иде. Улым Артем безнең янда калды. Июньдә өйләндерергә җыенабыз. Әти-әниләрнең күбесе ул-кызларын шәһәргә чыгарып җибәрү ягында бит, – ди Геннадий Туюров. – Күп эшлисең, ял итмисең, дип безне кызганучылар да бар. Нишләтәсең, йөрәк шундый. Берәү дә тик тормый. Кемдер сыер сава, кемдер тирес түгә... Кайчак, гаиләне эшкә җигеп, дөрес яшәмимме әллә, дип тә уйлап куям. Тик безне үзгәртеп булмый.

ВИДЕО – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

# ТҮЛӘҮЛЕ НИКАХ

**Озын гомерле никах өчен акча түли башларга мөмкиннәр. Халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы депутатлар яңа закон проектын тәкъдим итеп маташа. Түләү гаилә булып 20 ел һәм аннан да күбрәк вакыт яшәгән парларга каралган. Гаилә бәхетен акча саклый алырмы? Гаилә нигезендә нәрсә ятарга тиеш?**

kzn.ru

### Асылы нидә?

Шушы көннәрдә ЛДПР партиясе депутаты Ярослав Нилов 20 ел һәм аннан да озаграк ел бергә яшәгән гаиләләргә акча түләү тәкъдиме белән чыкты. Парламентарий сүзләренчә, хәзерге демографик хәлебезне исәпкә алып, гаилә институтына ярыйсы гына ярдәм булыр иде.

– Тиздән Гаилә һәм тугрылык көне. Шуңа күрә озак вакыт гаилә корып яшәүчеләргә бәйле федераль тәкъдимне карау дөрес булыр иде. Әгәр дә парлар 20 елдан артык никахта торалар икән, һәркайсына 20 мең сум түлик. Биш ел саен шулай эшләргә кирәк. Шулай ук төбәкләр өстәмә рәвештә башка социаль ярдәм чараларын билгеләргә хокуклы булачак, – дип тәкъдим итә Ярослав Нилов.

Акча түләүне бәллүр туйдан башларга кирәк дип саный депутат. Ягъни 15 ел бергә яшәүчеләрдән. Бу очракта аларга 15 мең сум бирергә тәкъдим ителә.

Ярослав Нилов әлеге закон проектын ЛДПР партиясенә нигез салучы Владимир Жириновскийга багышларга теләүләрен дә җиткергән. ЛДПР лидерының гаилә стажы шактый зур булганы билгеле.

### Шатлыкта да, кайгыда да

Фидания һәм Ләбиб Лероннарның гаилә стажы – 41 ел. Депутатлар тәкъдиме тормышка ашса, аларга да озын гомерле никах өчен акча түләргә тиешләр, димәк. Гаилә учагын саклаучы Фидания ханымнан бу тәкъдимгә карата нинди фикердә булуын сорадык.

– Мондый тәкъдим турында нәрсә әйтим? Өзелер дәрәҗәгә җиткән никахны бу гына туктатмас, билгеле. Икенче яктан караганда, хәзер акчаны беренче урынга куя торган буын үсеп җитте. Бәлки, алар өчен бу күпмедер дәрәҗәдә стимул да булыр. Гаилә тормышы тоташ чәчәктән һәм шатлыктан гына тормый, авырлыгы да килә, тормыш сабырлыкны сынап кына тора, – диде ул. – Шуңа күрә бу тәкъдимне, бәлки, дәүләт тарафыннан гаиләгә игътибар арту, дип аңларга кирәктер. Әллә ничә еллар бергәләп шатлык-сөенечләрен дә, авырлыкларын да бергә кичкән әби-бабайларны беләм. Көннәрдән беркөнне аларга акчалата бүләк бирелә икән, моңа шатланырга гына кирәк! Пенсияләр зур түгел, бер ярдәм булыр иде.

| Ел | Гаилә коручылар | Аерылышучылар | Аерма |
|---|---|---|---|
| 1960 | 1499581 | 184398 | +713% |
| 1970 | 1319227 | 396589 | +232% |
| 1980 | 1464579 | 580720 | +152% |
| 1990 | 1319928 | 559918 | +135% |
| 1995 | 1075219 | 665904 | +61% |
| 2000 | 897327 | 627703 | +42% |
| 2005 | 1066366 | 604942 | +76% |
| 2010 | 1215066 | 639321 | +90% |
| 2015 | 1161068 | 611646 | +89% |
| 2020 | 770857 | 564704 | +36% |

*Россия буенча мәгълүмат*

Фидания ханым фикеренчә, тормыш авырлыгын ялгызы күтәргәннәрне, балаларын сыңар канат булып тәрбияләп үстергәннәрне дә онытмаска кирәк. «Алар өчен дә файдалы булган акыллы тәкъдим кертсеннәр иде», – ди ул.

Саба районындагы Явлаштау авылында гомер итүче Рәзинә һәм Илшат Галимҗановлар 29 ел бергә. Кем әйтмешли, тәҗрибәсез түгелләр. Өч балага гомер биргәннәр, хәзер менә Рәзинә ханым – үзе дә каенана. Хөкүмәт бирә торган акчага бишкуллап риза булыр идек, ди.

– Хәзерге вакыт белән элеккесен – без тормыш корган чакларны чагыштырсаң, җир белән күк арасы инде. Элек акча юк иде, колхоз акча түләмәде. Ничек яшәлгәндер, белмим! Хәзер исә акча күпме булса да җитми. Капканың теге ягына чыксаң да, акча кирәк. Булган кадәренең бәрәкәте булсын, дибез, – ди хуҗабикә. – Хөкүмәт, шундый тәкъдимне тормышка ашырып, акча бирсә, без риза. Хәзер бәби тапканга да акча бирәләр. Безнең чорда декрет акчасы да булмады. Минем соңгы балама гына декрет акчасы чыкты. Инде шул 20 елдан артык торган өчен түләү булса, начар түгел.

Рәзинә апаның яңа гаилә корганнарга киңәше дә бар:

– Кавышканнар икән, торсыннар. Бер-берсен хөрмәт итеп яшәсеннәр. Аңлашырга, санлашырга кирәк. Хәзер яшьләрне уйлыйбыз бит инде. Рәхәтләнеп яши торган булсыннар иде! – ди ул.

### Өйләнгәндә җырлыйлар, ә өйләнгәч?

Акча белән кызыктырып кына гаилә институтын саклап калу мөмкинме? 20 ел түгел, 1 елын да яши алмаган парларны аерылышуга нәрсә этәрә? Гаилә нигезен ныгытуга тагын нәрсәләр стимул була алыр иде? Әлеге сорауларга җавапны психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева белән эзләдек.

Психолог сүзләренчә, акча түләү кебек тәкъдимнәр гаиләләрне сакларга азмы-күпме ярдәм итәргә мөмкин. «Дөресрәге, гаиләне саклап калырга бер сәбәп була ала. Бигрәк тә матди яктан ярдәм көткәннәргә, акчаны мотивация итеп күргәннәргә. Психолог буларак, мөнәсәбәтләренә нокта куярга теләүче парлар белән еш очрашырга туры килә. Акча ягын гына түгел, парларның психологик халәтенә бәйле тәкъдим турында да уйлансыннар иде», – ди белгеч.

Аерылышуларның сәбәпләренә килгәндә, биредә дә әлеге дә баягы акча мәсьәләсе кабыргасы белән килеп баса. «Яшьләр матди яктан өлгермичә өйләнешә дә аерылыша. Кредит, бурычлар, ата-аналар, туганнар белән бергә яшәү – болар барысы да аерылышуга китерергә мөмкин», – ди белгеч.

Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева сүзләренчә, көндәлек мәшәкатьләр белән очрашу да – парларның мөнәсәбәтләре өчен сынау. «Төшенкелек, кәефсезләнү, апатия ише хисләргә бирелергә мөмкин. Депрессиягә кадәр үк барып җитү дә ихтимал», – ди ул.

Араларны суыта торган тагын бер сәбәп – ике арада хөрмәт хисе булмау.

– Бер-береңне ишетә һәм тыңлый белмәү, юл куймау – төп сәбәпләрнең берсе. Миңа гаиләләр дә әнә шул сәбәп белән еш килә. Тагын берсе – бер-береңнән канәгать булмау, гел тәнкыйтьләп тору. Ягъни пардагының берсе икенчесен башта бик идеальләштерә. Бергә яши башлагач, ал «күзлек»не салырга туры килә. Чынбарлык син теләгәнчә булмаска да мөмкин. Сәбәпләрне ачыклау, үз-үзең белән эшләү урынына мөнәсәбәтләргә нокта кую юлын сайлыйлар, – дип аңлатты психолог.

Гаилә төшенчәсенә карата ике кешенең ике төрле караште булуы да тормышта кыенлыклар тудыра. Мәсәлән, хатын карьера турында хыяллана, ди, ә ир ат аның өйдә утыруын тели. Яисә ике кешенең бала тәрбияләүгә карашы ике төрле булырга мөмкин.

Аерылышуга илтә торган сәбәпләр арасында хыянәт, тормыш сынаулары, психологик басым ясау (абьюз мөнәсәбәтләр), психологик тайпылышлар (наркомания, хәмергә бәйлелек, комарлы уеннар) да бар.

Психолог әйтүенчә (аның җавапларыннан да чамаларга була), хәзерге заманда гаиләләрнең таркалуына ике кешенең психологик яктан тормышка әзерлексез булуы китерә. «Шәхес буларак, кешеләр үз өстенә җаваплылык алудан курка. Хәзер күпчелек үзе турында, үз максатлары турында гына уйлый. «Мин» беренче урында. Ә гаиләдә үзең турында гына уйламыйсың бит. Күпләр проблемадан кача. Бу «бала позициясе» дип атала. Ягъни, «нишләп әле мин моны хәл итәргә тиеш» дип, мәшәкатьтән чыгу юлын эзләп тормый», – ди ул.

Гаиләне саклап калырга тагын нәрсәләр ярдәм итә ала соң?

– Хакимият акчалата ярдәм чаралары турында даими кайгыртып тора анысы. Минемчә, социаль проектларга да күбрәк игътибар бирсеннәр иде. Шулай ук психологик ярдәм турында да онытмаска иде. Әйткәнемчә, низаглар, аңлашылмаучанлыклар белән очрашкан парлар мәсьәләне хәл итү юлын аерылышуда гына күрә. Алар белән эшләргә кирәк. Мактанып әйтү түгел, үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: берничә гаиләне таркалудан саклап калганым бар. Психологик терапия, проблеманың сәбәпләрен ачыклау бәрабәренә бу. Җәмгыятьтә сыйфатлы ярдәм күрсәтерлек белгечләр күп булсын иде. Яшь парларга яши башлаган чорда ярдәм аеруча кирәк бит. Гаилә ул – команда. Аларга менә шуны җиткерергә кирәк, – дигән фикердә белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

### ФИКЕР

**Сәйдә абыстай АППАКОВА:**

– Гаиләдә аңлашылмаучылык чыккан, үпкәләшкән саен өйдән чыгып китмиләр, әти-әнигә барып зарланмыйлар. Алар инде үз вазыйфаларын тулысынча үтәгән: сине үстергән, тәрбияләгән, хәер-фатихасын биреп, никахын укыткан, туен ясаган. Ә син аларны кайгыга саласың, ике арадагы гаилә мөнәсәбәтләрен, ир белән хатын арасындагы аңлашылмаучылыкка аларны да өстерисең. Кемгә җиңел моннан? Ике кеше тыныч кына уздырып җибәрерлек үпкәне дүрт кеше тикшерә. Ир белән яшисең, гаиләле буласың килгән икән, юкка-барга чәчрәмә, җаен тап, акыл белән эш ит. Рус халык мәкалендәгечә: «Таудан чана шуасың килгән икән, чанасын тауга үзең тартып мен». Шул чагында гына тирләп-пешеп чана шууның ләззәте була.

## ГАМӘЛДӘГЕ ТӨП ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ

**БАЛАЛАРГА БЕРДӘМ ПОСОБИЕ**

Йөкле хатын-кызлар һәм 17 яшькә кадәрге балалы гаиләләр өчен пособие яшәү минимумыннан кимрәк керемле гаиләләргә бирелә. Тагын бер шарты: балалар һәм аларның ата-аналары, Россия гражданлыгына ия булып, безнең илдә яшәргә тиеш. Түләү билгеләнгәндә, гаиләнең керемнәре һәм милке, шулай ук ата-ананың мәшгульлеге исәпкә алына. Бердәм пособие социаль ярдәмнең инде гамәлдәге берничә чарасын берләштерә: беренче атналарда учетка баскан йөкле хатыннарга айлык пособие; вакытлыча эшкә сәләтсез булган очракта һәм ана булу сәбәпле, мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга бала карау буенча пособие; 3 яшькә кадәр, 3 яшьтән 7 яшькә кадәр һәм 8 яшьтән 17 яшькәчә булган балаларга айлык түләүләр.

**АНА КАПИТАЛЫ**

2023 елда беренче бала туганда ата-аналар 589,5 мең сум алачак, бу 2022 елга караганда 65 мең сумга артыграк. Әгәр гаиләдә икенче бала туса, ана капиталы суммасы 779 мең сумны тәшкил итәчәк. Ләкин гаилә беренче балага сертификат алган булса, бу очракта дәүләт ярдәме күләме 189,5 мең сум булачак, бу 2022 елга караганда 20,9 меңгә күбрәк.

**БАЛА ТУГАЧ БИРЕЛӘ ТОРГАН ПОСОБИЕ**

2023 елда бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие 23011 сумны тәшкил итә.

**ИПОТЕКА**

Россиядә күпбалалы гаиләләргә ярдәм итү программасы гамәлдә, аның нигезендә дәүләт ипотека кредитын тулысынча яки өлешчә түләүгә 450 мең сумга кадәр акча бүлеп бирә. Мондый ярдәмгә өченче яисә аннан соңгы баласы 2019 елның 1 гыйнварыннан соң туган гаиләләр хокуклы.

## 15 май | Дүшәмбе

### ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ» ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». Телесериал 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество»16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татар халык җырлары» 0+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Малика Гельмутдинова. Доброта, спасающая мир 16+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Янам мәхәббәт дулкынында». Марат Фәйрушин 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». Телевизион нәфис фильм (субтитрлы) 16+
15.25, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

### 1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Михаил Гаврилов, Сергей Пускепалис, Агния Дитковските. «ТРЕЙДЕР» (S) 16+
23.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
00.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
01.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
01.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+

### РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ольга Будина, Андрей Чернышов, Ирина Купченко, Нина Усатова, Татьяна Васильева, Светлана Немоляева, Лариса Удовиченко, Сергей Степанченко. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Ольга Красько, Олег Алмазов, Александр Ратников, Сергей Мухин, Николай Лунин, Татьяна Кузнецова, Михаил Владимиров, Владимир Литвинов. «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ» 16+
03.45 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

### МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 «Здоровый образ. Регби» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 18.40, 22.40 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Хоккей. Чемпионат мира. Чехия – Казахстан. Трансляция из Латвии 0+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Громко». Прямой эфир
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. Германия – США. Прямая трансляция из Финляндии.
18.55 Хоккей. Лига Ставок Большой тур Сборной. Белоруссия – Россия. Прямая трансляция из Белоруссии
21.15 Хоккей. Чемпионат мира. Финляндия – Швеция. Прямая трансляция из Финляндии
23.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
00.25 «Наши иностранцы» 12+
00.55 Хоккей. Чемпионат мира. Чехия – Латвия. Трансляция из Латвии 0+
03.05 Новости 0+
03.10 Регби. PARI Чемпионат России. «Красный Яр» (Красноярск) – «Динамо» (Москва) 0+
05.05 Триатлон. Мировая серия. Женщины. Трансляция из Японии 0+

### НТВ
04.55 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Пётр Баранчеев, Алексей Шевченков, Василий Бриченко, Михаил Хмуров. «БОРЩИ» (S) 16+
22.15, 00.00 Владимир Епифанцев в детективном сериале «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
00.45 Илья Шакунов в детективном сериале «БЕЗДНА» (S) 16+
03.20 Детектив «ПЕТРОВИЧ» 16+

### ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.45 «Тест на отцовство» 16+
11.00 «Понять. Простить» 16+
12.15 «Порча». «Чудовище» 16+
12.45 «Знахарка» 16+
13.20 «Верну любимого» 16+
13.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «ДЕНЬ СВЯТОГО ВАЛЕНТИНА» 16+
19.00 «СЧАСТЬЕ МЕНЯ НАЙДЁТ» 16+
23.30 «Понять. Простить» 16+
00.45 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.45 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «ВСЁ К ЛУЧШЕМУ 2» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА
05.40 «Герой 115». Документальный фильм 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
10.55 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Мы наш, мы новый...» 12+
12.30, 13.25, 15.05 «КРАПЛЕНЫЙ». Телесериал. 1-я – 5-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Бронепоезда». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ТОРПЕДОНОСЦЫ» 12+
01.25 «Легендарные самолеты. Су-25. Огнедышащий «Грач». Документальный фильм 16+
02.05 «КРАПЛЕНЫЙ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+

## 16 май | Сишәмбе

### ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «АЛМАШ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «СТАЛИННЫ ЮК ИТҮ» ЯШЕРЕН ОПЕРАЦИЯСЕ». Телесериал 12+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Татар халык җырлары» 0+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Азербайджанские ковры 6+
00.50 «Соотечественники». Александр Патраков. С чистого листа 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 18.20, 21.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». Телевизион нәфис фильм (субтитрлы) 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00, 19.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+

### 1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
19.50 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ТРЕЙДЕР». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
02.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+

### РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Ольга Будина, Андрей Чернышов, Ирина Купченко, Нина Усатова, Татьяна Васильева, Светлана Немоляева, Лариса Удовиченко, Сергей Степанченко. «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР. ВОСЕМЬ ЛЕТ СПУСТЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Ольга Красько, Олег Алмазов, Александр Ратников, Сергей Мухин, Николай Лунин, Татьяна Кузнецова. «МОСКОВСКАЯ БОРЗАЯ» 16+
03.45 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

### МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Лучшие из лучших» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55 Новости
07.05, 15.30, 18.40, 21.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 Хоккей. Чемпионат мира. Словакия – Канада. Трансляция из Латвии 0+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир.
15.00 «География спорта. Стамбул» 12+
16.15 Хоккей. Чемпионат мира. Словения – Норвегия. Прямая трансляция из Латвии.
19.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. Финал. УНИКС (Казань) – «Локомотив-Кубань» (Краснодар). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/2 финала. «Интер» (Италия) – «Милан» (Италия). Прямая трансляция
00.55 Хоккей. Лига Ставок Большой тур Сборной. Белоруссия – Россия. Трансляция из Белоруссии 0+
03.05 Новости 0+
03.10 Баскетбол. Единая лига ВТБ. Матч за 3-е место. ЦСКА – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
05.05 Триатлон. Мировая серия. Мужчины. Трансляция из Японии 0+

### НТВ
04.55 Детективный сериал «МОСКВА. ЦЕНТРАЛЬНЫЙ ОКРУГ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.50 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Сериал «БОРЩИ» (S) 16+
22.15, 00.00 Детективный сериал «ЧИНГАЧГУК» (S) 16+
00.45 Детективный сериал «БЕЗДНА» (S) 16+
03.20 Детектив «ПЕТРОВИЧ» 16+

### ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45 «Понять. Простить» 16+
12.00 «Порча». «Зверь» 16+
12.30 «Знахарка» 16+
13.05 «Верну любимого» 16+
13.40 «Голоса ушедших душ» 16+
14.15 «СИЛЬНАЯ ЖЕНЩИНА» 16+
19.00 «МЕЖДУ НАМИ ВЫПАЛ СНЕГ» 16+
23.30 «Понять. Простить» 16+
00.45 «Порча» 16+
01.15 «Знахарка» 16+
01.45 «Верну любимого» 16+
02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «КОЛЫБЕЛЬ НАД БЕЗДНОЙ» 16+
05.50 «По делам несовершеннолетних» 16+

### ЗВЕЗДА
05.10 «КРАПЛЕНЫЙ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
10.55 «ГОСУДАРСТВЕННАЯ ГРАНИЦА». Телесериал. «Мы наш, мы новый...» 2-я серия 12+
12.30, 13.25, 15.05 «КРАПЛЕНЫЙ». Телесериал. 6-я – 9-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Вторая мировая: пламя и сталь». Документальный сериал. «Тяжелые танки» 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «СВИДАНИЕ НА МЛЕЧНОМ ПУТИ» 12+
01.20 «Восход Победы». Документальный сериал. «Курская буря» 12+
02.05 «КРАПЛЕНЫЙ». Телесериал. 7-я – 10-я серии 16+

## Белдерү

**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Кадастровый инженер: Елисеева Анна Андреевна (почтовый адрес: 420029, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д.17, офис 218, адрес электронной почты: 2582972@mail.ru, контактный телефон: +79600482972). Номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность 39 328, СНИЛС: 136-282-280-56, является членом СРО АКИ «Поволжье».

Выполняются кадастровые работы в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:255801:65 (Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, садоводческое некоммерческое товарищество «Сосновый», участок 65). Номер кадастрового квартала: 16:24:255801. Кадастровые номера смежных земельных участков: 16:24:255801:61, 16:24:255801:62, 16:24:255801:66, 16:24:255801:64, 16:24:255801:259.

Заказчиком кадастровых работ является Чистякова Татьяна Николаевна. Собрание по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д.17, офис 218 16 июня 2023 г. в 9 часов 30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218. Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 12 мая 2023 г. по 16 июня 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 12 мая 2023 г. по 16 июня 2023 г. по адресу: 420029, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218. Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:24:255801:61, 16:24:255801:62.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА**

Кадастровый инженер: Елисеева Анна Андреевна (почтовый адрес: 420029, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д.17, офис 218, адрес электронной почты: 2582972@mail.ru, контактный телефон: +79600482972). Номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность 39 328, СНИЛС: 136-282-280-56, является членом СРО АКИ «Поволжье».

Выполняются кадастровые работы в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:24:255801:66 (Республика Татарстан, Лаишевский муниципальный район, Орловское сельское поселение, садоводческое некоммерческое товарищество «Сосновый», участок 66). Номер кадастрового квартала: 16:24:255801. Кадастровые номера смежных земельных участков: 16:24:255801:61, 16:24:255801:65, 16:24:255801:332, 16:24:255801:259.

Заказчиком кадастровых работ является Ануфриева Людмила Алексеевна. Собрание по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д.17, офис 218 16 июня 2023 г. в 9 часов 30 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Пионерская, д. 17, офис 218. Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 12 мая 2023 г. по 16 июня 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 12 мая 2023 г. по 16 июня 2023 г., по адресу: 420029, Российская Федерация, Республика Татарстан, г. Казань ул. Пионерская, д. 17, офис 218. Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:24:255801:61.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# БАЛЫ БАЛСЫЗ, ТОЗЫ ТОЗСЫЗ...

**Тәм тоймау соңгы елларда аеруча еш очрый торган күренешләрнең берсенә әверелде. Күпләр моның өчен коронавируска «рәхмәтле». Әлеге чирне йоктыручылар тәм генә түгел, ис сизмәүдән дә зарлана. Белгечләр исә, тәм тою сәләте югалу күп кенә башка чирләрнең билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә. Тәм сизмәүгә бармак аша карау нәрсәсе белән куркыныч? Аны булдырмас өчен нәрсә эшләргә кирәк?**

**Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА белән шул хакта сөйләштек.**

**:: Тәм тою сәләте ник югала?**

– Иң беренче чиратта бу тәм тою рецепторлары зарарлану аркасында килеп чыга. Авыз куышлыгының лайлалы тышчасына инфекция эләккәндә, тәкерек бизе эшчәнлеге бозылганда, баш миенә зыян килгәндә дә кеше тәм тоймый башлый. Альцгеймер, Паркинсон кебек картлык авыруыннан, калкансыман биз авыруларыннан, шикәр чиреннән интеккән кешеләрне дә еш борчый ул. Кайбер антибиотикларны эчкәннән соң, организмга тимер, B, $B_{12}$ витаминнары җитмәгәндә дә тәм тою сәләте юкка чыгарга мөмкин.

**:: Коронавирус йоктыручылар да баштарак тәм сизми башлаудан зарлана иде бит...**

– Әйе, тәм тоймый башлау – коронавируска хас төп билгеләрнең берсе. Чир йоктыруның беренче көннәрендә, иң беренче чиратта, борын һәм йоткылыкның лайлалы тышчасы шешеп чыга. Бу исә ис һәм тәм сизү рецепторларына да «бәрә». Кайчак ковид баш миенең ис, тәм сизү өчен җаваплы өлешләрен дә зарарлый. Гадәттә, кеше коронавирус йоктырганнан соң 2–3 атна вакыт үткәч, яңадан тәм сизә башлый. Чирне авыррак уздырган очракта кеше ярты ел буе да тәм тоймыйча яшәргә мөмкин.

**:: Тәм сизү сәләте протез кию аркасында да югала аламы?**

– Югала ала. Өске казналыкларда тәм тою рецепторлары урнашкан. Протез кигәндә алар тулысынча каплана. Шуңа күрә кеше ашаган ризыгының тәмен дә сизмәскә мөмкин.

**ТЕЛНЕҢ КАЙСЫ ӨЛЕШЕ НИНДИ ТӘМ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ?**



vk.com

### АВЫЗ ҺӘРЧАК ТӘМ ТОЙСЫН, ДИСӘҢ...

- ✓ Тешләрне даими рәвештә көнгә ике тапкыр чистартырга кирәк.
- ✓ Ашаганнан соң авызны чайкатырга да онытмагыз.
- ✓ Дөрес туклану да гадәткә керсен.
- ✓ Куллар да һәрчак чиста булсын!
- ✓ Организм витаминнарга кытлык кичермәсен.
- ✓ Тәм тою рецепторларын уятып җибәрү өчен, ашарга әзерләгәндә кулланылган тәмләткечләрне дә төрләндерергә онытмагыз.
- ✓ Елга ике тапкыр стоматологка барып, тешләрне тикшертеп торуны гадәткә кертегез.

**:: Организмдагы мондый хилафлыкны ничек дәвалыйлар?**

– Иң беренче чиратта табиб тәм сизү сәләтенең нәрсә аркасында югалуын ачыклый. Әгәр ул билгеле бер чир аркасында югалган булса, ул әнә шул авыруны дәвалауга керешәчәк. Әгәр кеше ниндидер дару эчүе аркасында тәм сизми башлаган икән, аның дозасын киметергә яки бөтенләй башка препаратка үзгәртергә туры киләчәк. Тәм тоймау организмда яман шеш, баш мие имгәнү, авыз куышлыгы зарарлану аркасында пәйда булган икән, операция ясарга мөмкиннәр.

**:: Тәм сизмәүне вакытында дәваламау нәрсәсе белән куркыныч?**

– Тәм сизмәвегезне чамалап алуга кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Юкса тәм тоюның нәрсә икәнен гомерлеккә онытуыгыз бар. Тәм сизмәвенә бармак аша караган кешенең киләчәктә ашказаны эшчәнлеге бозылырга, хәтта паралич сугарга мөмкин.

Файдалы

## Яфраклы табиб

Бүлмә гөлләре һаваны чистартып кына калмыйча, бик күп кенә чирләрдән дә дәвалый.

**АЛОЭ.** Бу гөлнең яфраклары бүлеп чыгарган махсус матдәләр линолеумнан таралган агуларны йота. Алоэ – кислород чыганагы. Шуңа аны йокы бүлмәсенең иң түренә куегыз. Алоэ суы томау төшүне, ашказаны авыруларын дәвалый. Ә юылган һәм икегә бүленгән яфракларын ярага куярга була. Ул яраларны тиз төзәтә, яхшы дезинфекция чарасы булып тора.

**ЯРАН ГӨЛ.** Яран гөл бүлмәдә җыелган һаваны яңарта, микроблар һәм артык дымга каршы көрәшә. Ә җәен чебеннәрне куркыта. Бу гөл аш, йокы бүлмәсе өчен яхшы. Яранның исе кан басымын төшерә, йокылый алмый интеккәндә булыша.

**КАКТУС.** Ул компьютердан чыккан нурланышны да йота.

**МИЛӘҮШӘ.** Аларга карап торган кеше депрессиядән арына. Миләүшә барлык бүлмә өчен дә туры килә. Ул тынычландыра, төрле төсләре белән әйнең ямен арттыра.

**ФИКУС.** Ул бүлмәне кислород белән баета, тузан суырткыч кебек, начар агуларны җыя.

**Үзем сынадым**

### СӨТ БУЛЫШТЫ

Герпес чыгып тилмертә. Соңгы арада бер ысулның файдасын күрә башладым. Мамык тампонны 1,5 процентлы сөткә манып, герпес чыккан урынга сөртергә кирәк. Сөтне юмагыз, кипкәнче тотыгыз. Моны 2–3 сәгать саен кабатларга кирәк. Кичкә герпесның эзе генә калачак.

Гөлфия ЗАКИРОВА. Казан

Тест

## Организмыңа магний җитәме?

**1 Кулларыгыз һәрчак корымы?**

а) кулларым һәрчак дымлы (2 балл);
б) әйе (0);
в) кайчан ничек инде (1).

**2 Аз калорияле диеталарда утырасызмы?**

а) әйе, даими рәвештә (2);
б) булгалый (1);
в) беркайчан да утырганым юк (0).

**3 Кузаклы үсемлекләрне айга бер тапкырдан да азрак ашыйсызмы?**

а) төрлечә була (1);
в) әйе (2);
б) юк, кузаклыларны һәрдаим ашыйм (0).

**4 Ризык сайлаганда составында минераль матдәләр булуга игътибар итәсезме?**

а) һичшиксез (0);
б) составын карарга онытқан чаклар да була (1);
в) беркайчан игътибар иткәнем юк (2).

**5 Шпинат, яшел фасоль кебек яшелчәләрне хәтта җәй көне дә атнасына 3 тапкырдан азрак ашыйсызмы?**

а) әйе (2);
б) юк (0);
в) кайчан ничек туры килә (1).

**6 Кыздырып алдыннан бәрәңгене суда озак тотасызмы?**

а) әйе, берничә сәгать суда тотканнан соң гына кыздырам (0);
б) чистартуга ук кыздырам (2);
в) төрлечә була (1).

**7 Төнлә аягыгызны көзән җыерамы?**

а) юк (0);
б) бик еш (2);
в) кайчак булгалый (1).

**НӘТИҖӘ**

**0–10 балл.** Организмыгызда магний җитәрлек. Дөрес туклану һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баруыгыз нәтиҗәсе бу!

**10–15 балл.** Магний запасы акрынлап кими бара! Соңгы арада стрессларга тизрәк бирешә башлавыгызны үзегез дә сизгәнсездер. Шуңа күрә тынычлык сакларга тырышыгыз, организмга физик яктан авырлык китерүдән дә сакланыгыз. Магнийга бай кешью, миндаль, фундук, кыздырылган көнбагыш, карабодай һәм минераль су белән дә дуслашырга туры киләчәк.

**15–24 балл.** Организмыгыз магнийга бик нык кытлык кичерә. Чарасын күрмәсәгез, бу ашказаны, йөрәк эшчәнлегенә дә зыян салачак. Көзән җыеру да күзәтелергә мөмкин. Кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итегез!

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

# САКЛЫЙЛАР ДА, ЯКЛЫЙЛАР ДА

**Бакчаны корткыч бөҗәкләрдән саклау өчен гел химик матдәләр генә куллану файдага түгел. Алардан саклый торган үсемлекләр дә булуын онытып җибәрмик. Үзләре файдалы яки матур булудан тыш, бөҗәкләрдән саклауда ярдәмче дә булган үсемлекләргә бакчагызда урын кызганмасагыз, файдасын күрми калмассыз.**

vk.com

**Күршесе килешәме?**

*Яшелчәләр рәхәтләнеп үссен, мул уңыш бирсен өчен, аларның күршеләрендә нәрсә үсүе мөһим икән. Кайсы килешә һәм кайсы килешми икәнлеген түбәндәге таблицадан карап белә аласыз.*

| КУЛЬТУРА | КИЛЕШӘ | КИЛЕШМИ |
|---|---|---|
| Томат | Рәйхан, кишер, борчак | Бәрәңге, борыч |
| Кыяр | Редис, кукуруз | Бәрәңге, яшел тәмләткечләр |
| Кишер | Борчак, суган | Укроп |
| Борчак | Кишер, редис | Суган, сарымсак |
| Салат | Кишер, редис | Кәбестә, петрушка |
| Ногыт борчагы | Кишер, кыяр | Суган, сарымсак |
| Редис | Кыяр, ногыт борчагы | - |
| Кукуруз | Борчак, ногыт борчагы | Помидор, ташкабак |
| Ташкабак | Кукуруз, ногыт борчагы | Бәрәңге, суган |
| Бәрәңге | Ногыт борчагы, кукуруз | Помидор, кыяр, борыч |

### Бәрхет гөл

Бәрхет гөл (бархатцы) тамырга зыян сала торган нематодалар – микроскопик зурлыктагы вак суалчаннардан котылырга ярдәм итә. Әлеге гөлне шулай ук гөблә, акканат һәм башка бакча бөҗәкләре яратмый. Шуңа күрә алардан котылыйм дисәгез, бәрхет гөлне күбрәк утыртыгыз.

### Рәйхан

Аның исе чебен, черки һәм башка бөҗәкләрне куркыта. Гадәттә, алар помидор, борыч кебек яшелчәләрне үз итә.

### Алтын чәчәк

Алтын чәчәктә (хризантема) табигый инсектицид – пиретрум бар. Ул бакча корткычлары – гөблә, акканат һәм үрмәкүч талпаннарын куркыта.

### Лаванда

Аның исе черки, борча кебек бөҗәкләргә ошамый. Лаванда янына кәбестә белән брокколи утыртсагыз уңарсыз, чөнки ул әлеге яшелчәләрне үз итә торган бөҗәкләрдән дә саклый.

### Бөтнек

Әлеге хуш исле тәмләткеч кырмыскалардан саклый. Җәй көне иялəшеп аптыратмасыннар дисәгез, аны өй тирәсенә утыртыгыз, эзләре дә булмаячак.

### Бәбрия

Аның кискен исе черки, чебен һәм башка бөҗәкләрне куркыта. Ә менә бәбрия (розмарин) янына утыртылган ногыт борчагы белән борчак яхшы уңыш бирәчәк.

**Белгеч киңәше**

## КЫРАУДАН СОҢ НИШЛӘРГӘ?

Апрель җылысына алданып, күпчелек бакчачылар теплицага үсентеләрен күчереп өлгергәннәр иде инде. Бәйрәм ялларындагы кыраулар сәбәпле, ачык һавадагы яшелчәләргә генә түгел, теплицадагы үсентеләргә дә зур зыян килде. Мондый вакытта елап утырудан файда юк. Кырау төшкән үсентеләргә ничек ярдәм итәргә соң?

**Бакчачы журналист Роза Нургалиева мондый очракта нишләргә кирәклеген әйтте.**

✓ *Иң беренче үсентеләр өстенә салкын су сибегез.*

✓ *5 л суга 1 ампула «Эпин-экстра» кушып сиптереп, үсентеләргә ярдәм итә аласыз. Бер атнадан тагын бер тапкыр кабатларга була. Аның урынына шулай ук «Циркон» препаратын да кулланырга мөмкин.*

**Тәмле булсын!**

**Гөлнара ГАБДУЛЛИНА рецептлары**

## ХИНКАЛИ

**Камыр өчен кирәк:** *500 г он, 250 мл сап-салкын су, 1 чәй кашыгы тоз.*
**Эчлек өчен кирәк:** *400 г сыер ите, 200 г су, 1 суган, 2–3 тырнак сарымсак, берәз кинза, паприка, «Хмели-сунели» тәмләткече, тәменчә тоз белән борыч.*

Онга тоз, боздай салкын су салып, тыгыз итеп камыр басабыз. Аны чама белән 1 сәгатькә суыткычка алып куябыз. Аннары эчлекне ясыйбыз.

Фаршка тәмләткечләр, блендерда изелгән суган белән сарымсак, туралган кинза, су салабыз һәм яхшылап болгатабыз.

Аннары камырны җәеп, эчлекне салып, хинкалилар бөгәбез. Аларны тоз белән кайнатылган суга салып, 6–8 минут пешереп алабыз.

## ҖИҢЕЛЧӘ ТӘМЛЕ САЛАТ



**Кирәк:** *черри помидоры, кызыл суган, сарымсак, укроп.*
**Соус:** *1 чәй кашыгы бал, 5 аш кашыгы зәйтүн мае, 2 аш кашыгы лимон согы, тәменчә тоз, кара борыч, паприка, рәйхан.*

Савытка катламлап сарымсак, суган, укроп һәм помидорны салабыз. Соус өчен кирәкле әйберләрне аерым савытта болгатабыз. Аннары әзер соусны яшелчәләр өстенә салып, савытны капкач белән каплап, яхшылап селкетәбез һәм суыткычка бер сәгатькә куеп торабыз. Шашлык янына бирү өчен бик тәмле һәм җиңел салат әзер!

**Исеңдә тот!**

### Юшкынны бетерә

Чәйнеккә утырган юшкынны аш серкәсе ярдәмендә бетереп була. Чәйнек эченә 1:2 нисбәтендә аш серкәсе белән су салыгыз. Кайнап чыкканнан соң акрынрак утта 20–30 минут чамасы кайнатыгыз. Чәйнек эче юшкыннан бик җиңел арыначак. Аннары аны яхшылап юарга һәм чайкатырга киңәш ителә.

### Көйгән савыт-сабаны чистарта

Савыт-сабаны чистарту өчен, түбәндәге катнашманы кулланып карагыз. 100 г вакланган кер сабыны, 400 мл кайнар су, 3 аш кашыгы горчица порошогы, 3 аш кашыгы сода, 4 аш кашыгы нашатырь спирты (8 ампула). Башта кайнар суга вакланган сабынны салып эретергә. Аннары аңа, 30 градуска кадәр суынгач, сода, горчица, нашатырь спиртын салып болгатырга һәм яхшылап ябыла торган савытка салып куеп суытырга. 3–4 сәгатьтән әлеге катнашма куера. Аның белән көйгән кастрюльләрне, кашык-чәнечкеләрне чистартырга мөмкин.

**Белеп тор!**

## *Нәни розалар*

Роза – гөлләр патшабикәсе генә түгел, ә бакча патшабикәсе дә. Чөнки аны яратмаган, бакчасында үстереп карамаган хатын-кыз юктыр. Аның биек һәм тәбәнәк үсә торган сортлары була. Клумбаларны бизәү өчен, гадәттә, биек үсми торган сортларын сайлыйлар.

Озын булып үсми торган Флорибунда, Нина Вейбул, Ред Найт һәм Румба сортлары клумбаларда бик матур күренә. Тагын да тәбәнәгрәк – биеклеге 20–50 сантиметр чамасы була торган Лос-Анджелес, Клементина, Джевел, Лавандер, Амулет, Литл Баккара, Розмарин, Колибри дигән сортларны сайласагыз, алар да җәй буе бакчагызны ямьләр.

## ЦИКЛАМЕН ДЫМ ЯРАТА

• Бүлмә шартларында цикламеннар 25 ел үсә ала. Җәй көне аларны ачык туфракка күчереп утыртырга мөмкин.

• Цикламен дымны бик ярата, аны төбенә вак таш тутырылган савытка утырту кирәк. Ул су бөркүне бик яратып бетерми. Бу гөл утәли җилне өнәми, әмма салкынча һаваны ярата.

• Сатып алуга күчермәгез, 5 көн көтегез. Киң һәм бик тирән булмаган чүлмәккә утыртыгыз.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

# КӨН ДӘ МЕҢ СОРАУ

**Тормыш иткәндә, адәм баласының теге яисә бу мәсьәләгә бәйле соравы тумый калмый. Аларга дин күзлегеннән дә карарга өйрәнеп барабыз. Бүгенге сәхифәбездә укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга Раил хәзрәт ФӘЙЗРАХМАНОВ ачыклык кертте.**

**? Дога белән сүрә арасында нинди аерма бар?**

ИЛҮЗӘ С.

Дога ул – синең ихтыяҗларыңны Аллаһы Тәгаләдән сорау. Безнең һәркайсыбызның нәрсәгә дә булса мохтаҗлыгы бар. Кемгәдер саулык кирәк, кемгәдер – мал, бала кирәк. Менә шушы барча кирәк-яракны Аллаһы Тәгаләдән сорыйбыз.

Сүрә дигәннән, китап мисалында карыйк. Китапны кулга алсак, ул төрле бүлекләрдән тора. Ул бүлекләрнең темалары бар. Сүрәләр дә Коръәннең төрле бүлеккә бүлә. Әйтик, «Бәкарә» («Сыер») сүрәсе. Шул сүрәдә дога да, гыйбрәтле хикәяләр дә, хөкемнәр дә булырга мөмкин. Ягъни гади генә әйтсәк, барлык файдалы мәгълүмат тупланган бүлек сүрә дип атала.

**? Матурлык салонында хатын-кыз өйләнгән ир-аттан чәч кистерсә, гөнаһ булып саналамы?**

Лилия ЗӘЙДУЛЛИНА

Биредә аның өйләнгәнме, юкмы икәне мөһим түгел. Алар бер-берсенә чит икән (ягъни абый-сеңел, әти-кыз һ.б. түгел), аларга бер-берсенә кагылырга ярамый. Хәдистә әйтелә: «Минем башыма энә кадасалар, чит хатын-кызга кагылуга караганда ул күпкә хәерлерәк». Чит хатын-кызларга кагылудан сакланырга кирәк. Шөкер, хәзер бит хатын-кызлар өчен – хатын-кыз чәчтарашлар, ир-атларга ир-атлар бар. Иман өчен, диндарлык өчен дә аларга бару хәерлерәк булыр.

**? Нишләп намаз укыганда хатын-кыз ир-аттан арттарак басып торырга тиеш? Бу – хатын-кызны түбәнсетү түгелме соң?**

ГӨЛНУР

Һичшиксез, бу – пәйгамбәребез (с.г.в.) әмере. Ә аңа бу хөкемне Аллаһы Тәгалә җиткерергә кушкан. Хатын-кызга ир-атка караганда тыйнаграк булырга кирәк. Динебездә әйтелә: «Ир-атларга иң хәерле саф – алда, хатын-кызларга – артта». Хикмәте шунда: Аллаһы Тәгалә ир-атларны шулай яраткан: аларга гүзәл затларга карата мәхәббәт салган. Хатын-кыз янында булганда ир-атның шәһвәте уяныра, аның турында уйларга мөмкин. Бу исә уйны гыйбадәттән аера. Фетнәдән ерагайту, Аллаһы Тәгалә гыйбадәтеннән аермау өчен, шулай тиешле. Бу хатын-кызны түбәнсетү түгел, ә гыйбадәтне тагын да камилрәк итеп үтәү өчен кирәк.

**? Өшкерүчеләргә бару гөнаһ саналмыймы?**

Исемем редакция өчен генә

Юк, гөнаһ түгел, бу рөхсәт ителә. Әмма үз-үзеңне өшкерү хәерлерәк. Хәзер бу хакта китаплар да бар. Коръән аятьләрен телефоннан да, компьютердан да ачып тыңлый алабыз, әлхәмдулилләһ. Пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә шундый сүзләр бар: «Җәннәткә хисапсыз керүчеләр – өшкерү өчен башкаларга мөрәҗәгать итмәүчеләр». Әмма бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк: хәзерге көндә дини кырыгалдарлар да күбәйде.

dumrt.ru

Дин дип, үзләренең мәкерле эшләрен кылалар, Коръәндә, хәдисләрдә булмаган әфсеннәр уйлап табалар, дәвалыйбыз, диләр. Моны кәсепкә әйләндерәләр. Өшкерүчеләргә барыр алдыннан, башта җентекләп тикшерергә кирәк: алар, чынлап та, Коръәнгә мөрәҗәгать итәме?

**? Дога укый башласам, йокым килмәсә дә, авызым ачыла. Нишләп алай икән?**

ӘМИР Н.

Намаз, дога укыганда, гомумән, берәр гыйбадәт вакытында мондый хәл күзәтелә икән, бозым, сихер, күз тигән булу ихтимал дигән сүз. Күбрәк Коръән укырга, тыңларга, үзеңне өшкерергә кирәк.

**? Бала тапканнан соң кайчан намазга кайтырга ярый?**

ДИНӘ С.

Бала тапканнан соң чыга торган кан нифас дип атала. Нифас каны төрле хатын-кызда төрлечә була. Кемдәдер – 30, кемдәдер – 40 көн. Иң күбе – 40 көн. Хатын-кыз үзенең халәтенә карарга тиеш. Кайчан нифас килүе бетә, шуннан соң госел алып, чистарынып, намазга басарга була.

**? Каһвә эчәргә яратам. Ул хәләлме?**

ЧУЛПАН

Әйе, хәләл. Чөнки хәрам дигән дәлилләр юк. Ачыктан-ачык дәлилләр булмагач, каһвәне хәрам дип чыгара алмыйбыз. Әгәр табиб сәламәтлеккә бәйле рәвештә каһвә эчүне тыйса, бәлки, хәрам дияргә мөмкин. Чөнки без үз сәламәтлегебезгә зыян салырга тиеш түгел, ул – аманәт.

**? Яңа фатирга күченергә телибез. Өй ашын ничек дөрес итеп уздырырга икән?**

Хәбил КАМАЛИЕВ

Шунысын да аңларга кирәк: өй ашын уздыру мәҗбүри гамәл түгел. Аны уздырсаң, яхшы. Уздыруның максаты – Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү, рәхмәт әйтү. Шуңа күрә болай итәргә, тегеләй эшләргә дигән кагыйдәләр юк. Туганнарны, дус-ишләрне җыеп, корбан чалып, хәзрәт чакырып, вәгазьләр сөйләп, аш уткәрсә, бик яхшы. Һәр кеше мөмкинлегенә карый.

## Хикмәтле сүз

- «Ирләргә охшаган хатын-кызны, хатын-кызга охшарга теләгән ирне ләгънәт көтә».
- «Адәм баласы тутыра торган капчыклар арасында корсактан да начар капчык юк».
Сабырлык дигәнең бигрәк тә балалар авырганда кулланылган дарулар турында сүз барганда сынала икән. Ник дигәндә, ата-аналарның күбесе шул ук температура төшерә торган, тамак авыртканда электән кулланган даруларны кул астында тотарга тырыша. Хәтерләсәгез, узган ел даруханә киштәләреннән температураны төшерә торган барыбызга билгеле «Нурофен» дару, «Амоксиклав» дигән балалар антибиотигы юкка чыкты. Әмма ата-аналар ул вакытта да бу даруларны алу җаен тапты. Күпләр аларны чит илдән кайтарту ягын карады. Бу даруларны кулдан гына сатып алучылар да булды.

11 нче номерлы шәһәр балалар хастаханәсе педиатры, Татарстанның атказанган табибы Гөлназ Азизова исә мондый хәвефләнүләрне урынсыз дип саный.

– Россиядә җитештерелгән барлык дарулар, шулай ук антибиотиклар да чит илдән кайтарылган препаратлар кебек үк нәтиҗәле. Әйтик, балалар авырганда элегрәк еш кулланылган «Нурофен»ны хәзер «Ибупрофен» алыштырды. Ул да нәкъ шулай ук тәэсир итә: баланың тиз арада температурасы төшә, сызлаулары басыла. Теләсә кайсы табиб хәзерге вакытта даруханәдә нинди дару бар, нинди юк икәнлекне яхшы белә. Әгәр ул теге яки бу препаратның аналогын язып бирә икән, курыкмыйча алырга, кулланырга кирәк, – ди табиб.

### Файдасыз булса сатылмый

«Таттехмедфарм» оешмасы җитәкчесенең дарулар белән тәэмин итү буенча урынбасары Надия Шемякина да шул фикердә. «Бөтен илләр дару җитештерү өчен кирәкле чималны Кытай белән Һиндстаннан ала. Шуңа күрә даруларны барыбыз да бер үк төрле җитештерә», – ди ул.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының клиник фармакологы, профессор Максим Максимов сүзләренә караганда, даруларның үзебездә җитештерелгәннәре дә оригиналь препаратлар кебек үк нәтиҗәгә ия. Аналог даруларның файдасы булмаса, аларны сатуны бөтенләй тыярлар иде, дип саный ул.

– Дарулар закон тарафыннан расланган тәңгәллек процедурасы уза һәм бары тик шул очракта гына даруханәләргә эләгә. Әгәр тормыш өчен мөһим даруларга алмаш кирәк икән, Россиядә җитештерелгән аналогларны да сайларга була. Бу очракта даруханәдә провизор ярдәм итә ала, әгәр бераз катлаулырак очрак икән, табиб белән киңәшләшергә кирәк, – ди ул.

Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген бер даруга үзебездә җитештерелгән ун аналог туры килә. Авыртуны баса торган даруларның, антибиотикларның 30–50ләп исемдәге алмашы бар. Кагыйдә буларак, теге яки бу даруның аналогы ул халыкара мәйданда барлыкка килгәннән соң биш ел чамасы вакыт узгач кына пәйда була. Закон шулай куша. Димәк, якын киләчәктә без кулланган күп кенә даруларга алмашлар саны тагын да артачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

### ДАРУЛАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ АНАЛОГЛАРЫ КҮПМЕ ТОРА?

| | ДАРУ | | АНАЛОГЫ | |
|---|---|---|---|---|
| Төре | Исеме | Уртача бәясе (сумнарда) | Исеме | Уртача бәясе (сумнарда) |
| авыртуны баса | Баралгин | 392 | Аналгин | 55 |
| аллергиядән | Зиртек | 213 | Цетринакс | 72 |
| ютәлдән | Лазолван | 390 | Амброксол | 59 |
| ашкайнату эшчәнлеген яхшырта | Мезим | 299 | Панкреатин | 43 |
| эч авыртудан | Омез | 162 | Омепразол | 88 |
| йөрәк даруы | Панангин | 374 | Аспаркам | 61 |
| буыннар сызлаганнан | Фастум-гель | 459 | Кетопрофен | 125 |
| кан басымын көйли | Энап | 401 | Эналаприл | 47 |
| калкансыман биз авыруыннан | L-тироксин | 360 | Эутирокс | 120 |
| вируслы авыруларга каршы | Эргоферон | 510 | Гриппферон | 300 |
| | Амиксин | 670 | Лавомакс | 461 |
| тән тиресен төзәтә | Бепантен | 960 | Декспантенол | 256 |

**Ишеттегезме?**

## Пандемия тәмам

**COVID-19 китереп чыгарган пандемия тәмамланды. Бөтендөнья Сәламәтлек саклау оешмасы бу көннәрдә шундый белдерү ясады. Билгеле булганча, тормышыбызда коронавирус дигән зәхмәт пәйда булгач, 2020 елның 11 мартында дөньяда пандемия игълан ителде. Шуннан бирле барлыгы 3 ел да 2 ай үткән.**

**Шул вакыт эчендә:**

- дөньяда коронавирус йоктыруның **765** миллион очрагы теркәлгән, **20** миллион кешенең гомере өзелгән;
- Россиядә **23** миллион кеше ковид йоктырган, **400** мең кеше үлгән;
- Татарстанда **205362** ковид йоктыру очрагы теркәлгән, **2** меңнән артык кешенең гомере өзелгән.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы генераль директоры Тедрос Гебрейесус белдерүенчә, пандемия тәмамлану тынычланырга вакыт дигән сүз түгел. Коронавирус беркая да юкка чыкмады, ул әле дә булса тормышыбызда яши бирә. Әйтик, әле узган тәүлектә генә Россиядә – ковид йоктыруның 2344, Татарстанда 24 яңа очрагы теркәлгән.

«Әле узган атнада гына дөньяда һәр өч минут саен ковидтан кеше үлә иде. Бу әле – без белгән очраклар гына. Бүген дөнья күләмендә меңәрләгән кеше терапия бүлекләрендә гомерләре өчен көрәшә, тагын миллионлаган кеше коронавирус салган зыян белән көрәшеп яши. Чир йоктыручылар саны кискен артудан туктады. Пандемия бетерелде дип шул сәбәпле генә игълан ителде», – ди белдерде ул.

# «БЕЗ БУЛГАНДА, ИЛ ХУР БУЛМАС»

## ТАТАРСТАН ЕГЕТЛӘРЕ КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘ КИТӘ

«Татар-информ»

**«Ирләр булып туганбыз икән, без үз гаиләбезне, туган җиребезне, Ватаныбызны сакларга тиеш», – ди контракт буенча хәрби хезмәт узарга теләүчеләр. Узган ел Татарстанда 2 меңләп кеше шундый теләк белдергән. Быел саннар тагын да күбрәк булачак, дип фаразлана. Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алуның Казандагы пунктында Ватан алдындагы бурычын үтәргә теләүчеләрдән көненә 40ка якын гариза кабул итәләр. Булачак солдатларны сайлап алуга бәйле үзгәрешләр дә бар.**

**Ирекле эш**

Алмазга – 32 яшь. Казанда туып-үскән егет узган елдан бирле контракт буенча хәрби хезмәт уза. Әле яңа гына ялга кайткан.

– Дусларым, танышларым махсус хәрби операция зонасында хезмәт итә. Аларга ничек тә булышасым, илемә ярдәм итәсем килде. Шуңа күрә контракт буенча хәрби хезмәт узарга теләк белдердем, – ди Алмаз. – Мин солдат ашының нәрсә икәнен яхшы беләм. Диңгез пехотасында хезмәт иттем. Хезмәттәшләрем белән гел аралашып, очрашып торабыз. Арада кабат хезмәткә китәргә теләк белдерүчеләр шактый. Мин дә Ватан алдындагы бурычымны үтәргә әзер. Безнең кебек ир-егетләр булганда, ил хур булмас. Әти-әнием каршы килмәде. Кечкенә чакта үзләре гел: «Чын ир-егет булып үс, улым», – дип әйтәләр иде. Ялга кайткач, әтием, күкрәгемә төртеп: «Батыр», – диде. Минем өчен моннан да зур бәя юк.

Хәрби хезмәткә контрактны сәламәтлеге буенча яраклы 18дән алып 60 яшькә кадәрге ир-атлар төзи ала.

– Әгәр кандидатның белгечлегенә кытлык зур булса, 65 яшькә кадәр дә килешү төзергә рөхсәт ителә, – ди Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алуның Казандагы пункты җитәкчесе Евгений Токмаков.

Шушы арада гына хәрби хезмәткә бәйле тагын бер яңалык гамәлгә керде. Эш шунда ки, моңа кадәр урта һөнәри яки югары белеме булган кеше хәрби хезмәткә алынмыйча гына турыдан-туры контракт буенча хезмәт итә ала иде. Хәзер мондый мөмкинлек 18 яше тулган, запаста булмаган кешеләргә дә бирелә. Иң мөһиме – сайлап алу пунктында әңгәмә узарга кирәк. Һәр кандидат белән шәхсән очрашып сөйләшәләр, барлык шартларны аңлаталар. Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алуның Казандагы пункты мәгълүматларына караганда, хәзер алар көненә 40ка якын гариза кабул итә.

– Өч-дүрт айдан башлап биш елга кадәр килешү төзергә мөмкин, – ди Евгений Токмаков. – Шунысы да бар: әгәр кеше бер ел һәм аннан да күбрәк вакытка исәпләнгән контракт төзи икән, бу очракта ул 195 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү дә алачак. Махсус хәрби операциядә катнашучы «контрактчы»ларга 204 мең сум һәм күбрәк айлык акча түлиләр. Шулай ук аларга күпсанлы ташламалар, премияләр, дошман техникасын тар-мар иткән өчен өстәмә түләүләр дә каралган.

Яңа чакырылган солдатларны хәрби бүлекчәләргә озаталар. Бирелә алар кирәкле күнекмәләр ала һәм шуннан соң контракт төзүчеләрне хәрби хәрәкәтләр зонасына озаталар.

– Контракт буенча хәрби хезмәт – ирекле эш. Без һәр кандидат белән аерым эшлибез. Мәсәлән, әгәр кешенең машина йөртү таныклыгы бар һәм ул техниканы үзенең биш бармагы кебек белә икән, мондый кандидат хәрби хезмәт өчен ремонтлау бүлекчәсен сайлап алырга, БТР яки танк ремонтлап файда китерергә мөмкин. Без егетләрне иң элек яхшы әзерлек бирүче хәрби бүлекчәләргә озатабыз, – ди Евгений Токмаков.

Татарстан хәрби комиссариаты китергән саннардан күренгәнчә, бу ел башыннан бирле республикада 1 меңгә якын кеше контракт буенча хәрби хезмәт узу теләген белдергән инде. Контракт буенча хәрби хезмәткә алыну өчен, гаризаларны хәрби комиссариатка барып та, Дәүләт хезмәтләре порталы аша да тапшырырга мөмкин. Электрон гаризаларны РФ Оборона министрлыгы сайтындагы шәхси кабинет аша да кабул итәләр.

– Электрон рәвештә тапшырылган гаризалар сайлап алу пунктларына җибәрелә. Бу кандидат белән үзебез элемтәгә кереп, алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген аңлатабыз һәм аны якындагы хәрби комиссариатка юллыйбыз, – ди Евгений Токмаков. – Булачак солдатлар контракт буенча хәрби хезмәт узу теләге турында үзләре дә чакыру комиссиясендә әйтергә мөмкин.

### КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТ УЗУЧЫЛАРГА ҺӘМ АЛАРНЫҢ ГАИЛӘЛӘРЕНӘ СОЦИАЛЬ ТАШЛАМАЛАР

- Россия Оборона министрлыгы хисабына туплаулы ипотека системасы аша тиз арада торак алу мөмкинлеге.
- Хезмәт итү чорында торак белән тәэмин итү яки аны арендага алып торган өчен компенсация.
- Хәрби-медицина учреждениеләрендә бушлай тикшерену, дәвалану һәм реабилитация узу.
- Федераль бюджет хисабына тормышны һәм сәламәтлекне иминиятләштерү.
- 20 ел хезмәт иткәннән соң пенсиягә чыгу хокукы.
- Хәрби хәрәкәт ветераны статусы һәм аңа тиешле ташламалар (кайбер салымнардан азат итү, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташламалар һ.б.).
- Кредит һәм салым каникуллары.
- Балаларны вузда укыту өчен бюджет урыннары.
- Махсус хәрби операциядә катнашучының балигъ булмаган һәр баласына 20 мең сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган акча.
- Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын балалар бакчасы һәм мәктәптә бушлай ашату.

**Бу мөһим!**

### БАРЫСЫ ДА ТИГЕЗ

Россия Президенты Владимир Путин махсус хәрби операциядә катнашучыларга бирелә торган түләүләрне тигезләү тәкъдимен хуплады. Билгеле булганча, Федерация Советы Рәисе беренче урынбасары Андрей Турчак күптән түгел шундый тәкъдим белән чыккан иде. Аның әйтүенчә, махсус хәрби операциядә катнашучыларга бирелә торган түләүләрдә гаделсезлек сизелә. Мәсәлән, мобилизация башлангач, үз теләге белән китүчеләргә 195 мең сум акча бирелә. Аның кайда һәм кем булып хезмәт итүе дә мөһим түгел. Контракт буенча хезмәт итүчегә исә бу акча алгы сызыкта булган очракта гына түләнә.

– Сез күтәргән мәсьәлә бик мөһим. Кулына корал тотып, Россия өчен көрәшүчеләр өчен шартлар тигез булырга тиеш. Безгә кешенең кайсы төркемгә керүе түгел, аның Ватанына булган мөнәсәбәте мөһим. Шартлар тигез булырга тиеш, – диде Владимир Путин Турчак белән очрашуда.

# Акчалата түләүләр

**БЕР ТАПКЫР 195 МЕҢ СУМ КҮЛӘМЕНДӘ ТҮЛӘҮ**
*(килешүне бер ел һәм аннан да озаграк вакытка төзегән очракта).*

**МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯ ЗОНАСЫНДА АЕНА 204 МЕҢ СУМНАН БАШЛАП АЙЛЫК ТҮЛӘҮ** *(хәрби дәрәҗәсе, вазыйфасы һәм хезмәт итү елына карап)*:

| | *Бер айга түләү* |
|---|---|
| укчы | 204 000+ |
| пешекче | 211 000+ |
| машина йөртүче | 211 000+ |
| гранатометчы | 211 000+ |
| пулеметчы | 211 000+ |
| өлкән машина йөртүче-электрик | 216 000+ |
| өлкән сапер | 216 000+ |
| өлкән телефонист | 219 000+ |
| команда-штаб машинасының радиостанциясе җитәкчесе | 226 000+ |
| штаб инструкторы | 226 000+ |
| отделение командиры | 232 000+ |
| отделение командиры-взвод командиры урынбасары | 242 000+ |

**Һөҗүм итү операциясендә катнашкан очракта, контракт буенча хәрби хезмәт узучыга һәр тәүлек өчен өстәмә рәвештә 8000 сум акча түләнә.**

### Таныклык бирәләр

Казан янәшәсендәге районнарның берсендә яшәүче 29 яшьлек Рифат әле яңа гына контракт буенча хәрби хезмәт узарга теләк белдергән.

– Ватанпәрвәрлекне һәркем үз үрнәгендә күрсәтергә тиеш. Ирләр булып туганбыз икән, гаиләбезне, туган җиребезне, Ватаныбызны сакларга кирәк. Махсус хәрби операция зонасында ике туган абыйларым хезмәт итә, – ди ул. – Мин үлемнән курыкмыйм. Көндәлек эшем дә куркыныч. Армия сафларыннан кайткач, инкассатор булып эшли башладым. Корал көн дә кобурада йөри. Яшерен-батырын түгел, контрактны фатир сатып алырга бераз акча юнәтеп булмасмы дип төзедем. Өйдәгеләр исән-сау әйләнеп кайтуымны көтәргә вәгъдә итте. Армиядә диңгезче идем. Югалып кала торганнардан түгел, кыскасы.

Социаль ташламалар һәм гарантияләр – контракт буенча хезмәт итүнең тагын бер өстенлекле ягы, ди Евгений Токмаков.

– Контракт төзүчеләр хәрби хәрәкәт ветераны статусын һәм тиешле ташламаларны ала. Моннан тыш, хәрбиләрнең тормышы һәм сәламәтлеге иминиятләштерелә. Алар ташламалы ипотека яки хезмәт итү чорына торак белән тәэмин итү хокукыннан файдаланырга мөмкин. Хәрбиләрнең балаларына ял лагерьларына бушлай юлламалар бирәләр. Моннан тыш, вузларда бюджет урыннары да каралган, – дип аңлаттылар Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алуның Казандагы пунктында.

Контракт буенча хезмәт итәргә теләүчеләр яшәү урыныңдагы яки якындагы хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итә ала. Моның өчен паспорт һәм хәрби билет та җитә.

Контракт буенча хәрби хезмәткә кайчандыр ялгышлык кылып, хөкем ителүчеләрне дә алырга мөмкиннәр. Дөрес, бу экстремистлар, террорчылар, хөкүмәткә каршы җинаять кылучылар, көчләүчеләр кебек авыр җинаятьләр буенча рәшәткә артында утырып чыгучыларга кагылмый.

– Хәзер без бу мәсьәләдә кеше хәленә керергә тырышабыз. Тормышта төрле хәлләр килеп чыгарга, бу яшьлек хатасы булырга да мөмкин. Шартлы рәвештә ирегеннән мәхрүм ителүчеләр, шартлы рәвештә вакытыннан алда иреккә чыгучыларга да кайбер ташламалар каралган. Андыйлар белән сөйләшүләр алып барабыз, – дип аңлаттылар Контракт буенча хәрби хезмәткә сайлап алуның Казандагы пунктында.

Шунысын да искәртик: сайлап алу пунктында хөкем ителүчеләр белән аңгәмә коралар. Аның тормыш тарихын җентекләп өйрәнәләр. Шуннан соң гына комиссия вәкилләре соңгы сүзне әйтәчәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

### Сорау – җавап

**?Хәрби хәрәкәт ветераны таныклыгын алу өчен кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?**
МАНСУР С.

**Татарстан Хәрби комиссариаты:**
– Әлеге таныклыкны бирү мәсьәләсен тикшерү гариза тапшыручы кеше яшәгән хәрби округның хәрби хәрәкәт ветераны таныклыгын рәсмиләштерү һәм тапшыру буенча мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү комиссиясенә йөкләнгән. Моның өчен документларны комиссиягә хәрби исәпкә баскан яки яшәү урыны буенча хәрби комиссариат бүлекчәсе аша тапшырырга кирәк. Әгәр гражданинның хәрби хәрәкәттә катнашуы раслаучы документлары югалган булса, аларны эзләү белән хәрби комиссариат мөстәкыйль рәвештә шөгыльләнәчәк. Искәртеп узабыз: әлеге статуска ия булучыларга айлык акчалата түләү дә каралган.

Көчле рухлылар

## РЕЗЕДӘ ВӘГЫЙЗОВА:
# «Кешедән көтә торган заман түгел»

**Рухың нык булу кирәк! Кайчак сау-сәламәт кешеләр булдыра алмаганны эшли алар. Тормышны яратып яшәгәнгә, эшләре дә уң була. Сере гади: шөкер итеп, рәхмәтле булып яши беләләр.**

Резедә Вәгыйзованың шәхси архивыннан

Актаныш районының Теләкәй авылында гомер итүче 45 яшьлек Резедә Вәгыйзова белән аралашкач, әнә шундый уйлар белән яши башлыйсың. Кечкенә генә кызга шулкадәр күп үҗәтлек, тырышлык каян килгәндер. Әбит кайчандыр табиблар Резедәнең әнисенә баланы хастаханәдә калдырып чыгарга да киңәш биргән була.

– Мин – «бәллүр» кеше. Табиблар телендә остеогенез дип атала ул. Кул-аяклар еш сынып, алар дөрес ялганмаганга гәүдә үсми кала. Минеке дә шулай. Туганда ук аяк-куллар тиешенчә булмый минем. Гомерлек авыру буласымны шунда ук беләләр. Әти-әниемә рәхмәт, алар мине ташламый. Әле дә терәк булып яшиләр, – дип сөйли Резедә.

Башкалардан гәүдә төзелеше белән генә аерыла ул. Вакытында теле ачыла, башкалар тәпи киткәндә, ул да шуышып йөреп китә. Булдырырлыгы кечкенәдән күренеп тора аның. Укырга-язарга да өйрәнә. Әтисе белән әнисе мәктәпкә күтәреп алып бара, күтәреп алып кайта. Кыш көннәрендә укытучылар өйләренә килеп укыта. Шулай итеп, Резедә 9 нчы сыйныфка кадәр укый.

– Элек физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен каршылыклар күп иде. Хәзер генә уңайлы ул. Интернетта бар да бар. Телисең икән укыйсың, телисең икән укытасың. Төрле һөнәрләргә дә өйрәнеп була. Ә мине эшкә өйдә өйрәттеләр. Әбием кечкенәдән бәйләргә өйрәтте. Уенчыклар бәйләргә яратам. Сәйләннәр белән дә үрергә өйрәндем. Кул эшләрем белән «Абилимпикс» бәйгесендә дә катнаштым әле. Анда икенче урынны яуладым, – ди Резедә.

Куллары алтын аның. 38 яшендә тегүчелеккә дә укып чыга ул. Резедәне бер урында тик утыртып булмый. Интернет аша бизнеска да керешкән. Шулай итеп, өстәмә акча эшли икән.

– Кемдер бирер әле дип көтеп утыра торган заман түгел. Башың эшли, кулларың бар, йөри алмасаң да, үрмәлисең икән, нигә әле мескенгә салышып ятарга? Тор да эшлә. Ниндидер үрләргә менәсең килә икән, тырышырга кирәк. Башкача мөмкин дә түгел. Булдыра алмаган кеше юк ул. Ялкаулар гына бар. Мин: «Булмаган җиргә тумаган», – дияргә яратам. Аңлагансыздыр инде, булдыра алмаган эш юк, җебегән кеше әле тумаган, диюем. Менә шул девиз белән яшим дә инде, – ди Резедә.

Үз девизына тугры ул. Булдырмаган эше юк. Шуышып барып җитә алмаган җиренә арбасында җилдерә. Әле менә гомерендә беренче мәртәбә самолетта очып, Белоруссиягә барып кайткан.

– Тормышны яратырга кирәк. Мин үземне бик бәхетле димен. Бәхетне кем ничек күрә бит инде. Үзеңне кирәкле итеп тойсаң, яратсаң, менә ул – бәхет. Кемгәдер ярдәм дә итә алсаң, инде монысы күккә ашканга тиң! Әти-әниеңнең, якыннарыңның янәшә булуы кирәк. Көч куеп эшләгән хезмәтеңә бәя бирсәләр, димәк, гомер заяә узмый. Үзем эшләгән бизнеста директор дәрәҗәсенә күтәрелдем. Интернет аша, кешеләр җыеп кына акча эшлим. Үз төркемем бар. Эшемне бик яратам, – ди ул.

Гел елмаеп кына тормыш бармавын белә Резедә. Күңеленә моңсу булган чаклар да бар аның. Андый вакытта кул эшенә тотына икән. Әмма төшенкелеккә бирелеп ятарга вакыт юк, тизрәк уйларны үзгәртеп, көлеп яшәргә ашыга. Ул болай да гел нур чәчеп тора. Күңеле дә матур аның. Үзе дә, тышкы матурлык түгел, күңел чисталыгы кирәк, ди.

– Хатын-кыз үзенең бәясен белергә тиеш. Алайса кешеләр гел үзләрен яратмыйча яши. Нинди бар шулай кабул итмиләр. Йә үзләрен таза диләр, йә ямьсез дип күңелләрен төшерәләр. Үзең яратмасаң, сине берәү дә яратмый. Юкка зарланып утырмагыз. Авыру килсә, бар да үзгәрә, – ди ул. – Минем кебекләргә әйтер сүзем бар: өйдән чыгарга куркып ятмагыз! Сез берәүдән дә ким түгел. Авыру тудым дип, яшәргә куркып торыргамы инде! Җиргә кеше юкка килми. Булдыра алганны эшләп яшәргә кирәк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

## РИШАТ ФАЗЛЫЙӘХМӘТОВ:

# «БЕЗНЕҢ ЧОРНЫҢ ҮЗ ҖЫРЧЫСЫ БУЛЫРГА ТИЕШ»

**Сүзгә сак, фикере төгәл, карашы моңлы. Ришат ФАЗЛЫЙӘХМӘТОВны әнә шулай бәяләргә буладыр. Сүзгә саклыгының, карашындагы моңның сәбәпләре, җыр тәэсире һәм эстрада проблемалары хакында булды бу әңгәмә.**

**:: Язмышка ышанасыңмы?**
– Ышанам. Минем белән булган бар нәрсә: шатлыгы да, кайгысы да – язмыш сынавы. Җырчы булу да тәкъдирдә язылган булгандыр. 4 яшемнән бирле җырлыйм бит инде, тикмәгә түгелдер. Юкса нәсел-нәсәптә башка җырчылар да юк. Әни – аш-су остасы, әти механик иде минем. Икесе дә сәнгатьне яраттылар. Берзаман безнең авылга – Мари Иле Республикасының Бәрәңге районындагы Мазарбашына – Фирзәр Мортазин килеп концерт куйган. Әтигә бик ошагандыр инде, малай туса, Фирзәр дип исем кушам дигән. Чак кына Фирзәр булмый калганмын мин.

**:: Ә Мари Иленнән Татарстанга килеп чыгуың?**
– Мәрхүмә әнием Мамадыш якларыннан минем, мөгаен, шуңа күңел Татарстанга тарткандыр. Башта Казан дәүләт мәдәният институтына укырга килдем, аннан шушында калдым инде. Әле дә күз алдында: әни белән сораша-сораша институтның тулай торагын эзләп таптык, аннары документларны тапшырдык та, мин аны ЦУМ янынннан автобуска утыртып җибәрдем. Студент еллары – иң күңелле чаклар. Зөлфәт Фәхретдинов, Руслан Галимуллин белән бер бүлмәдә яшәдек. Таңга кадәр сөйләшеп, көлешеп утырган вакытлар еш була иде.

**:: Үкенечең бармы?**
– Юк, бернәрсәгә дә үкенмим. Мин тормышымда булган бөтен нәрсәгә дә рәхмәтле. Кирәк дип тапкач, үзем белән булган хәлләрне ачыктан-ачык сөйләдем. Мин – гап-гади малай, тамашачы, бәлки, шушы гадилегем өчен хөрмәт итәдер. Ялгышларым да булды, хаталарым да. Ризыкны авыз итмичә генә тәмен белеп булмаган кебек, нииндидер адымның дөресме, хатамы икәнен ул адымны ясамыйча гына белеп булмый. Ялгышларым турында кабат искә аласым килми, фәкать шунысын гына әйтә алам: элеккеге Ришат белән хәзергесе арасында аерма бик зур. Мин инде хәзер фикерле, төпле. Элек, яшермим, өстәнрәк кенә уйлый идем.

**:: Үзгәрешләргә нәрсә сәбәпче булды?**
– Беренчедән, тормыш үзгәртте. Якын кешеләремне югалту кайгысын бер-бер артлы кичерергә туры килде. Башта бертуганым Рифат абый, йөрәге тотып, вакытсыз гүр иясе булды. Аның кайгысыннан әтием Нур бик бетеренде. Абыйдан соң алты ел гына яшәде ул, аның артыннан әнием Луиза китте… Шул ук елны әниенең әнисе – әби дә бакыйлыкка күчте. Аннан соң да кайгылар булып торды әле. Болар үз эчемә бикләнергә мәҗбүр итте. Яраткан кешесенә сынауны өеп бирә, диләр бит, шулай булгандыр. Аллаһы Тәгалә сынавын да, шул сынаулардан тартып чыгарырлык кешесен дә юлларыма чыгарды. Акыллы – атын, юләр хатынын мактар, ди. Мин хатыным Эльмирага таяныч булуы, ир итеп санлап торганы, ярдәм иткәне өчен рәхмәтле. Эльмираны тормышымда минем хәтта сәхнәдә үз-үземне тотышым да үзгәрде.

**:: Эльмира тамашачының игътибарын ничек кабул итә?**
– Әйбәт кабул итә, хәтта сөенә дә. Хатын-кызның игътибарын җәлеп итәсең, дип көнләшкәне юк һәрхәлдә. Нормальный ирләргә хатын-кыз карарга тиеш инде ул.

**:: Хатын-кыз, бигрәк тә сәхнә кешеләре үзләрен үзгәртү белән мавыга хәзер. Ясалма матурлык турында ни уйлыйсың?**
– Хатын-кыз үзен тәртиптә тотарга тиеш, дип саныйм. Бигрәк тә сәхнә кешесе үзен карарга тиеш. Үзенә ошый икән, үзгәрсен. Табигать хатын-кызны матур да, акыллы итеп тә яраткан. Нинди адымга барсалар да, акыл белән эш итсеннәр, сәламәтлекләренә зыян салмасыннар.

**:: Репертуарың да синең белән бергә үзгәрәме?**
– Әлбәттә! Дөрес, мин төрлесен җырлыйм. Тормышчан җырлар сайларга тырышам.

**:: Эстраданың төп проблемасы нәрсәдә?**
– Татар эстрадасының проблемалары шактый. Үзем халык җырларында тәрбияләнгәч, сәхнәдә нәкъ менә шундый моңлы, халыкның бәгыренә үтеп керердәй җырларның күбрәк булуын теләр идем. Хәзер «Телне югалтмас өчен нәрсә эшләргә?» дигән сорауны бик еш бирәләр. Җырны да шул максатта файдаланып була. Әмма теләсә кайсы белән түгел, мәгънәле җырлар белән генә татар теленә мәхәббәт уятырга мөмкин. Татарлыкны онытырга ярамый. Теләсә кайсы сәхнәдә син тамашачыга үз халкыңның вәкиле буларак кызыклы.

**:: Сәхнә – хәзер шабашка урыны, диләр...**
– Бу фикердә хаклык бар. Кызганыч, тавышы булган җырчылар зал тутыра алмый хәзер. Халык нишләптер ялтыравыкка алдана. Сәбәбе гади бер карагандa, без халыкка иярдек һәм тәрбия функциясен оныттык. Нишлисең бит, ияргү табыш китерә.

**:: Мөмкинлек булса, мәдәнияттә нәрсәне үзгәртер идең?**
– Худсоветларны кире кайтарыр идем. Җырларны да, җырчыларны да, гастрольләрне дә худсовет аша үткәрергә кирәк. Худсовет ярдәмендә генә элеккеге эзгә төшеп була.

**:: Үзеңнең яраткан җырчың бармы?**
– Мин барлык җырчыларны да хөрмәт итәм. Остазым Салават Фәтхетдиновтан күп нәрсә өйрәндем дип әйтә алам. Бәләкәй чакта безнең өйдә өч җырчының кассетасы бар иде. Болар – Салават абый, Хания Фәрхи, Айдар Галимов. Шуларны тыңлап үстем инде. Әмма аларны кабатларга тырышмадым. Үзеңне табарга кирәк. Үз юлымны таптым дип уйлыйм.

**:: Җырчы булмасаң, нинди һөнәр иясе булыр идең?**
– Авыл хуҗалыгын яратам. Мөгаен, шул тармакта үземә берәр эш табар идем. Хәер, комбайнда эшләгән бар инде. Авылда төп нигез буш булса да, сагынып кайтам. Анда бар да тәртиптә, әниенең гөлләре дә элеккечә чәчәк атып утыра. Авыл якын миңа.

**:: Кәефеңә нинди җыр туры килә?**
– «Үкенмә үткәннәргә».

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

### Блиц-сораштыру

**– Танылу сере нәрсәдә?**
– Тумыштан сәләтле булу һәм шул сәләтне үстерү өчен армый-талмый эшләү. Җырчы булып танылу турында сүз алып барсак, боларга өстәп, финанс ягының да тотрыклы булуы кирәк. Җыр яздыру, радио-телевидение рекламасы бүген арзан түгел. Әмма хикмәт акчада гына түгел. Моңсыз, әмма акчалы җырчы да эстрадага чыгып карый. Күпмедер эшли дә юкка чыга. Моң юк икән, ул барыбер тамашачы игътибарын озакка җәлеп итә алмый. Боларга өстәп, уңу да кирәк. Кемдер бик җиңел уңа, кемдер, таланты булса да, уңмый. Яшерен-батырын түгел, җырчы команда белән эшләгәндә генә уңышка ирешә ала.
**– Интернет ресурсларын файдаланып танылып буламы? Әйтик, шәхси яңалыкларың белән бүлешеп, халык игътибарын яуларга мөмкинме?**
– Интернет мөмкинлекләрен актив файдаланабыз. Әмма минем өчен ул 50гә 50. Бер яктан файдага, икенче яктан зыян салып куярга да мөмкин.
**– Илһам Шакиров кебек җырчы тагын туа аламы?**
– Илһам Шакиров кебек җырчы башка булмаячак. Ул үз чорында туган, яшәгән, үзеннән соң бай мирас калдырган. Безнең чорның үз җырчысы булырга тиеш.
**– Үзең турында фильм төшерсәләр, ул ничек аталыр иде?**
– «Минем исемдә» булыр иде.

< Ахыры. Башы 28 апрель, 5 май саннарында

## ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

# СИН КЕМ КЫЗЫ?

***

Камил икенче катта урнашкан бүлмәсенә җәяүләп күтәрелде. Хокук бүлегенең яртылаш ачылып торган ишегеннән кемнеңдер моңлы итеп җырлаган тавышын ишеткәч, туктап калды.

*Сандугачлар су эчәләр*
*Агыйделгә төшеп.*
*Нигә болай сагынам икән,*
*Үзәкләрем өзелеп?!*

«Кабинетыма үтәргәме, әллә «сандугач»ны өркетмәскәме? Эштән соң калып моңланып утырырлык булгач, юкка гына түгелдер. Иртәгә бүлек башлыгы Ирек Газиз улы белән сөйләшеп алырга кирәк булыр», – дип уйлаган арада, җыр да тукталды. Камил саклык белән, тавыш чыгармаска тырышып, эш бүлмәсенең ачкычларын тартып чыгарды.

– Хәерле кич, Камил Касыймович!

Камиләнең зәңгәр күзләре Камилгә тутырып карап тора иде.

– Хәерле кич, Камилә! Бик матур җырлыйсыз икән, махсус белем алганнардан да уздырасыз.

Төбәп әйтелгән бу сүздән Камилә кызарып куйса да, аңа күңелле икәне йөзенә чыккан иде.

– Рәхмәт, Камил Касыймович! Исән-сау йөреп кайтуыгыз белән!

Камил: «Кабинетка чакырсам, сөйләшеп утырырга иң кулай вакыт, бүләкне дә тапшырырмын», – дип уйлады.

– Камилә, кайтырга ашыкмасагыз, үтегез әле минем белән кабинетка.

Камилә бит очларын чокырлатып елмаеп куйды. Шушы чакыруны көтеп кенә торган диярсең!

Оксана булмагач, секретарь вазыйфасын үзенә үтәргә калды Камилгә. Ял итү бүлмәсендәге кәнәфидән Камиләгә урын күрсәткәч, чәйнекне кабызып җибәрде. Өстәлгә затлы конфетлар, печенье, җимешләр куелды.

– Йә, Камилә, хәлләр ничек, эшкә күнегәсезме?

– Әкренләп. Өйрәтүчеләрем яхшы, тырышам...

Камил Камиләгә туры карарга тырышмады. Гел Яүһәрия бит. Хәтта тавышлары охшаган. Үз-үзеннән куркып та куйды, ялгышып кочаклап алмасын тагын. Тик менә бер ягы гына әнисенеке түгел: Яүһәриянең дә Камил кебек җырларга әвәслеге юк иде. Нишләтәсең, Ходай бар кешене җырчы итеп тудырмый. Ә менә Камиләгә каян килгән шулкадәр моң? Камил үзләренең туган-тумачалары арасында да оста итеп җырлаган кешене белми. Бәлки, Яүһәрия яклаптыр?

– Бүген моңланып утырасыз, берәр сәбәбе бармы?

Камилә тагын елмайды.

– Камил Касыймович, сәбәбе – бары минем җырларга яратуымда гына. Үземне белә башлаганнан бирле җырлыйм мин. Әтиемнән күчкәндер ул моң миңа. Белсәгез иде сез аның ничек үзәкләрне өзәрлек моңлы тавыш белән җырлаганын!

Камилнең йөрәген нәрсәдер көйдереп алды. «Юк, әле бу гына Камиләнең Наил кызы булганын исбатламый, әллә ниләр уйлама», – дип үзен тынычландырырга тырышты. Камиләне үзенең кызы итеп бик күрәсе килә иде аның. Ничә еллар көттеләр бит алар кыз бала. Тик уллары Газинурдан соң Фәнәзия бер тапкыр да авырга узмады. Кыз бала наздан туа, диләр бит, әллә шул «наз» дигәннәре җитеп бетмәде микән?

Камил, уйларына бирелеп, Камиләнең янында утырганын да онытып җибәрә язды.

– Камил Касыймович!

– Тыңлыйм, Камилә!

– Беренче тапкыр күрү белән мин сезне яраттым!

Камил корт чаккан кебек сикереп торды.

– Камилә, сез... син...

Камил, беренче тапкыр кыз белән күрешкән егет сымак каушап, ни әйтергә белми аптырап калды. «Ә мин аны юаш кына бала дип торам, кара әле, моның бөтен көче йөрәгендә икән!»

– Камил Касыймович, мин тилене ачуланмагыз инде. Егерме ике яшькә җитеп беркемне дә болай ошатканым булмады. Ә сезгә беренче күрүдә үк гашыйк булдым. Бүген эшкә киләчәгегезне сизеп тоткарландым бит. Махсус, сезне күрер өчен.

– Камилә, тынычлан. Мине яратырга рөхсәт бирәм. Тик башкача, әтиеңне яраткан кебек.

vk.com

– Камил Касыймович, мин бакчага йөри торган бала түгел ич. Минем үз әтием дә бар яратырга. Ике әтинең миңа кирәге юк.

«Хокук бүлеген юкка бетермәгән, оста сөйли. Ачарга кирәк дөреслекне, юкса бу бала, кабинетка чакырып кертүемне дөрес аңламавы бар». «Камилә, эшләр болайга киткәч, әйтмичә булмый. Чөнки ялгыш адымны вакытында туктата белү мөһим», – дип башлады ул сүзен.

Камилә, ни сөйләсәгез дә, мин сезне яратудан туктамыйм, дигән кыяфәт чыгарып, Камилнең күзләренә текәлде.

– Камилә... Сез... син минем кызым.

– Камил Касыймович, миннән котылу өчен уйлап таптыгызмы моны?

– Мин – синең үз әниең – Яүһәриянең яшь чагында яратышып, кавыша алмаган кешесе. Алай гына да түгел, ул, син «әти» дип йөргән Наилгә, миннән авырлы килеш кияүгә чыккан. Мин аның йөкле икәнен белмәдем... Син боларны белгәч, бәлки, мине күралмас дәрәҗәгә җитәрсең. Ләкин мин яшермим, дөресен сөйлим.

Камилә шул арада кәнәфидән кул арасы гына яткан сумкасын үрелеп алды да, эченнән бер конверт тартып чыгарып, Камилгә сузды. Конвертның тышкы кыяфәте аңа бик күп еллар икәнен ачык күрсәтеп тора иде.

– Ачыгыз, эчендәге хатны укыгыз. Кычкырып укыгыз.

Камил карышып торуның файдасыз икәнен аңлап, Камиләгә буйсынды.

«Кызым, бердәнберем Камиләм! Синә бу хатны әтиең кулыңа өлгергәнлек аттестаты алгач кына бирер. Шулай сөйләштек аның белән. Бөтен теләгем синең бәхетле, озын гомерле булуың. Җиде айлык булып кына тусаң да (ике кило йөз грамм иде авырлыгың), олылар әйтмешли, Ходайга шөкер, бик тере бала булып үстең. Инде быел беренче класста укыйсың. Физкультура – иң яраткан дәресең. Беркөнне: «Әни, мин, үскәч, физкультура укытучысы булам», – дип сереңне дә ачтың. Шуны әйтәсем килә: мин каршы түгел, һөнәр сайлау үз иркеңдә булыр. Тик шулай да минем сине хокук белгече итеп күрәсем килә...»

– Ярый, шунда туктагыз, башкасы кирәкми, авыр миңа тыңларга. Үзем генә аулакта укырга яратам мин әнинең хатын.

Камил тагын буйсынды. Хәтта бу юлы аңа Яүһәрия эндәшкән кебек тоелды.

– Әтигә дә мин җиде айдан тугач, сүзләр җиткергәләгәннәр. Тик ул әнигә ышанган, аны җәберләмәгән. Хәтта генетик экспертиза ясарга да уйламаган. Беренче курсны бетергәч, үзем көчләп диярлек күндердем. Ризванов Наил кызы икәнлегемне раслаган документларым бар. Тик бу турыда икебез генә беләбез әти белән. Ул: «Әниеңә ышанмаган кебек булып чыга бит, беркемгә дә әйтмә бу турыда», – дип кисәтеп куйды мине. Әтинең икенче хатыны Яүһәрия Ризванова да белми хәтта экспертиза ясатып йөрүебез турында. Хәер, ул экспертизасыз да минем кем кызы икәнемне беләдер. Алар әни белән ахирәтләр булганнар. Әниемнең әллә күпме сере аңарда саклана, миңа да сөйләп бетергәне юк әле.

***

Фәнәзия кулындагы язу кисәген кая куярга белми иза чикте. Ертып ыргытырга да оныттыргамы? Тормышларыннан көнләшеп, юри араларын бозар өчен генә дә язган булулары бик мөмкин бит. «Ирегездән колак кагасыгыз килмәсә, япьяшь сөяркәсеннән тизрәк аерып алу чарасын күрегез. Изгелек теләүче» дигән сүзләр болай да соңгы вакытта Камилнең эшендә күбрәк тоткарлануына ризасызлыгы арткан шикле күңелгә өстәмә ризык булып кереп утырырга күп тырышлык сорамый иде. Әллә Камилнең үзенә укытыргамы? Гомер буе иренә ышанып яшәгән Фәнәзиянең җанын моңа кадәр аңа билгеле булмаган ямьсез хисләр капшый башлады. «Ичмасам, бертуганым да юк сер ачарлык. «Дустыңның да дусты булыр, ул да сөйләр дустына» дигән киңәшне гомер буе юлдаш итеп яшәгән Фәнәзия, күз яшьләрен сөртә-сөртә, телефоннан Камилнең номерын җыярга керешә. Телефонның теге ягыннан «Абонент недоступен...» дигән җавап кына ишетелде.

Камил кайтып кергәндә, Фәнәзия нервларны тынычландыра торган дару төймәләре кабып, залдагы диванда ятып тора иде.

Көндәгечә каршына килеп: «Әтисе, кайттыңмы?» – дип хәл сорашучы булмагач, Камил беренче булып үзе эндәште.

– Әнисе, нихәл?

– Башыма чыдый алмыйм, кан басымы күтәрелгән бугай, хәлем юк.

Камил төймәләре каптырылмаган кышкы тунныннан тиз генә бушанып, залга үтте. Төсе качкан Фәнәзияне күргәч: «Әнисе, хәзер ашыгыч ярдәм машинасы чакыртам...» – дип сүз башлаган иде дә, хатыны аның кулына уртага бөкләнгән кәгазь кисәге тоттырды.

Арада тынлык урнашты. Тек-тек-тек. Тек-тек-тек. Сәгать телләре нигә шулкадәр тавышланып йөриләр икән? Ичмасам, тышта буран да уйнамый, ул вакытта сәгать телләренең текелдәве дә ул кадәр ишетелмәс иде. Тек-тек-тек. Тек-тек-тек.

Камил акланып та маташмады, кире дә какмады. Әлеге минутта аңа Фәнәзиянең сәламәтлегеннән дә кыйммәт нәрсә юк иде: ул телефоннан ашыгыч ярдәм номерын җыярга керешә.

***

Камилә, эш сәгате беткәч, үзәк универмагка илтеп куярга такси чакыртты. Камил Касыймович белән шунда очрашырга сөйләштеләр бүген. Исәпләре – чәшке тун сайлау. Камилә башта карышып та карады. Беренчедән, Камил Касыймовичтан шундый кыйммәтле бүләк алырга кыенсынса, икенчедән, ул бит, гомумән, тун сайлый белми. Аңа ниндирәк фасондагы тун килешер? Бәлки, бөтенләй килешмидер әле?! Тик Камил Касыймович өзмәде дә куймады: «Алабыз һәм бетте!» Бер ай инде Камилә үзен төш эчендә йөргән кебек хис итә. Киноларда яки китапларда гына була торган хәлләрнең нәкъ аңа да килеп кагыласын ул башына да китерми иде. Я инде, аңа ярты ел элек: «Камил Касыймович дигән кеше – синең әтиең», – дип әйтсәләр, сумкасыннан справкасын алыр да, борын төпләрендә селкеп: «Минем әтием – Наил Ризванов!» – дип әйтер иде. Ә бүген алай дип әйтә алмый, чөнки Камил Касыймович экспертиза үткәреп, Камиләнең аның кызы икәнен исбатлады. Алай гына да түгел, Камиләнең әни-әтисе белән дә аңлашып килделәр. Олы йөрәкле кеше булганын тагын бер тапкыр исбатлады әтисе Наил. Әнисе исеменнән хат язучы да, справканы ничек кирәк, шулай итеп эшләткән кеше дә булып чыкты ул. Чөнки район җирлегендә кешеләр бер-берсен бик яхшы белә. Камиләгә бер генә «яхшылык теләүче» килеп чыкса да, эшнең ни белән тәмамланасын чамалаган әтисе Наил.

Камил Касыймовичка «әти» дип эндәшкәне юк әле Камиләнең. Аның әтисе берәү генә, шулай булып калыр да. Камил Касыймович үзе дә кыстамый. Әмма шулай да күп вакытын бүлә ул Камиләгә. Эштән соң еш кына җәяүләп Камиләне фатирына озатып куя. Сәгать ярым нәрсә турында гына сөйләшмиләр алар. Камилә әнисе турында әллә күпме яңалык белде, шәһәрнең алар яратып йөргән урыннарын ничә тапкыр барладылар. Камиләнең ризалыгы белән икенче оешмага эшкә дә урнаштырды Камил Касыймович аны. Гаиләсе белән таныштырырга да сүз биргән иде, җае гына чыкмый бугай әле.

Камилә универмагка килеп җиткәндә, Камил Касыймович урта яшьләрдәге бер хатын-кыз белән ишек төбендә басып тора иде. Камилә хатын-кызның Камил Касыймовичның хатыны – Фәнәзия икәнен чамалады. Һәм ялгышмады. Фәнәзиянең үзенә төбәлгән ягымлы елмаюлы карашын күргәч, каушавы басылгандай булды Камиләнең. Бер-берсен сәламләгәч, Камил Касыймович аларны якыннан таныштырды.

– Тун сайлаганда Фәнәзия апаңнан да остарак кеше табып булмас, дип уйладым. Һәм, гомумән, Камилә, ул синең иң якын кешеләреңнең берсе булып китәр, шулаймы, әнисе?

– Әлбәттә, әтисе! Син ышыклап барганда, арага җил дә кермәс!

Камил, яратып, Фәнәзиянең күзләренә карады.

# «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

## медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына языл

**П2435** – җомга саны **512 сум 70 тиен**
**П2409** – атнага дүрт тапкыр чыга **1227 сум 30 тиен**

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**
89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**

**Сертификатлар:**
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнена кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

# МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»
*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ 3 100 сум

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

*Анализлар. Күкрәк бизләренә УЗИ.*
*Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.*

**Адрес:** Салих Батыев ур., 1 йорт
Тулырак сайтта: nhkrt.ru

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.
Реклама 18+
ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШҮ СОРАЛА.


## Сканворд

Тракторга тагыла
Бура чималы
... кат!
Төрек борчагы
Татарның каймагы
«Фиат» автомобиле төре
«Татарстан-24» каналында «Мәдәни ...» тапшыруы
Җимерек
Халәт

Начар түгел, хуп
Казандагы спорт ТВ студиясе
Әдәби тәнкыйтьче Миләүшә ...
... һәм Зөя
Иоганн Себастьян ...
... Шакирҗан
... уникe кыз идек
Мәккә суы
Ызбада ятак-табын
...-мирәк
Сембер тимер аты
Европа күршесе
... Ширмән
Герасим дусты
Морза
Мужик!
7 нче химик элемент
... итек
«Просто ...» сериалы
Аны саклыйлар
Ир кешегә 70 төрле һөнәр дә ...
Әйләнгеч, туры түгел
Вертолет



Кисәкчә
Җиңелчә явыз
Совет йөк машинасы
Татар киеменә милли бизәгеч
Жай
Автомат
Шашлыкка кирәк
Петров һәм Сидоров дусты
Чех мотоциклы
Төшке һәм кичке була
Тинчурин актеры Зөфәр ...
Бернечә батальоннан тора
«Аккошлар тәрәзә кага, ...тәрәзәнне иртән»
Уку – аның белән кое казу
Том Сойерны уйлап тапкан
Ятьмә оя коручы бөҗәк

## Әз-мәз мәзәк

– Минем бу спектакльдә йоклыйсым килде.
– Ә минем – чыгып китәсем.
– Кур әле, нинди гади генә спектакль, ә тамашачыда нинди төрле хисләр уята.

***

Күктә укылган никах куркыныч, аннан егылып төшәргә мөмкин.

***

– Гарәп Әмирлекләрендә халык шәп яши.
– Аларда газ һәм нефть бар шул.
– Бездә дә бар бит.
– Ә аларда ничә миллион кеше яши?
– Бернечә миллион.
– Бездә дә бернечә миллион кеше яхшы яши.

***

Роялльгә караганда гитара уйнарга өйрәнү отышлырак. Бауман урамына роялльне күтәреп чыгып булмый.

## Сканворд җаваплары

**Горизонталь:** бүрәнә, сука, Хәбетдинова, рух, әйбәт, Болгар, без, УАЗ, сирәк, Халисә, Мария, кирза, урау, сер, әз, Ми, ли, АМО, усал, ип, ит, Иванов, Ява, аш, урмәкүч, энә.

**Вертикаль:** хәрабә, Муму, изү, урә, Харисов, Бах, Луара, АКМ, Галиуллин, нут, Азия, полк, мишәр, сәке, ач, би, ир, Уно, Баер, Алия, зәмзәм, Твен, агарту, азот.

## Беләсең килсә...

**1 Габделҗаббар Кандалый үзлегеннән нинди телне өйрәнгән?**
а) чуаш;
б) мари;
в) удмурт.

**2 Жир шарында иң киң таралган химик элемент:**
а) азот;
б) водород;
в) кислород.

**3 «Кубань» дип кайсы җирлекне атыйлар?**
а) Ставрополь крае;
б) Краснодар крае;
в) Ростов өлкәсе.

**4 «Шивә» дигән иске татар сүзе нәрсәне аңлата?**
а) шик, шөбһә;
б) диалект, җирле сөйләм;
в) агач сагызы.

Җаваплар: 1.а); 2.в); 3.б); 4.б).

Сәхифәне Данил САФӘРОВ әзерләде


**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Индекс П2435**
**Тираж – 14266 данә**

**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 265

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+